ҖОМГА
22 МАРТ
1940 ел
№ 67 (5867)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлеге 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—73, хатлар бүлеге 21—28, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—73, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

СТУДЕНТЛАРНЫ ПОЛИТИК-ТӘРБИЯЛӘҮ— ЗУР ӘҺӘМИЯТЛЕ ЭШ

Хәзерге көндә Советлар Союзының югары уку йортларында 600 меңгә якын студент укый. Югары уку йортларын тәмам итү белән алар производствоның командирлары—инженерлар, агрономнар, врачлар, укытучылар, фән работниклары булып эшләячәкләр. Аларның һәр кайсына гаять җаваплы, шул ук вакытта мактаулы бурычлар йөкләтеләчәк.

Партиябезнең XVIII нче съезды һәм бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин тарафыннан илебез алдына гаять зур һәм җаваплы бурыч куелды—Советлар Союзы Европаның иң алга киткән капиталистик илләрен һәм Америка Кушма Штатларын экономик яктан да якын ун-унбиш ел эчендә куып җитәргә һәм узып китәргә тиеш.

Илебез алдына куелган бу бөек бурычны уңышлы үтәүдә социалистик интеллигенциянең роле гаять зур. „Бу тарихи эштә безнең интеллигенциябез гаять дәрәҗәдә җаваплы урын алып тора. Культура кешеләре, техника һәм фән кешеләре, иске һәм яңа интеллигенция, безнең студентларыбыз һәм квалификацияле эшчеләрнең яшьләр белән тулыландырылучы кадрлары—болар барсы да совет халкына кирәк, яңа бөек бурычларны башкару өчен, чиратка куелган төп экономик бурычны тормышка ашыру өчен, өченче бишьеллык планны җиңүле рәвештә үтәү өчен кирәк. Безнең эшебезнең уңышлы чыгуы, СССР ның башка илләр белән экономик ярыш җәеп җибәрүенең уңышлы чыгуы һәм коммунизмның капитализм белән тарихи ярышының уңышлы чыгуы аларның эшчеләр һәм крестьяннәр хезмәтен оештыра алырлык булуларына, аларның үзләренең фәнни белемнәрен техникадан файдалану эшенә һәм хезмәт җитештерүчәнлеген барлык чаралар белән күтәрү эшенә бирә белүләренә бәйләнгән булачак". (Молотов).

Партиябезнең XVIII нче съезды тарафыннан куелган бөек бурычларны тормышка ашыруда актив катнашу өчен, безнең интеллигенциябезнең дөньяда иң революцион теория белән—марксизм-ленинизм теориясе белән коралланган булуы, идея-политик яктан туктаусыз үсүе таләп ителә. Шуның өчен дә студентларны—булачак врачларны, агрономнарны, укытучыларны, фәнни работникларны, дәүләт эшлеклеләрен, производствоның командирларын политик тәрбияләү, аларны марксизм-ленинизм теориясе белән коралландыру эше иң әһәмиятле бурычларның берсе булып тора.

Орденлы Татарстанның башкаласы булган Казан шәһәре—ул ВУЗ лар шәһәре. Казанда барлыгы 13 югары уку йорты бар, аларда 11 меңгә якын студент укый. Студентларныңабсолют күпчелеге, һич шиксез, марксизм-ленинизм белән — иҗтимагый үсеш һәм политик көрәш законнарын белү белән кораллану буенча тырышып эшлиләр, җәмагат эшләренә актив катнашалар. Ватан өчен, коммунизм өчен чын күңелдән бирелеп эшләүче патриотлар булып тәрбияләнәләр.

Ләкин, кайбер югары уку йортларында студентларның бер өлеше дисциплинаны бозу, тормыш көнкүрештә тотнаксызлык күрсәтү, югары уку йортларының эчке тәртипләрен бозу кебек ярамаган эшләрне эшлиләр, үзләренең студентлык исемнәренә тап төшерәләр.

Медицина институты студентларының бер өлеше марксизм-ленинизм курсы буенча үткәрелә торган лекцияләргә, семинарларга аз йөри. Кайбер студентлар занятие вактында язышып, үзара сөйләшеп утыралар, лекцияне рәтләп тыңламыйлар. Бу иптәшләр үзләренең идея-политик белемнәрен күтәрү өстендә нык- лап эшләмиләр. Педагогия институты студентлары арасында да марксизм-ленинизм курсы дәресләренә игътибарсыз карау, эчкечелек белән шөгыльләнү фактлары бар. Химико-технология, юридик институтларның кайбер студентлары, шулай ук, эчкечелек белән шөгыльләнәләр, дисциплинаны бозалар, дирекциянең приказларына буйсынмыйлар. Казан дәүләт университетында марксизм-ленинизм фәне буенча студентларның өлгерешe шактый түбән тора, дисциплинаны бозу фактлары еш кына кабатлана.

Бу фактлар барсы да бер нәрсә турында—студентлар арасында политик-тәрбия эшләренең куелышы канәгатьләнерлек булмау, уку дисциплинасының йомшак булуы турында сөйлиләр.

Политик-тәрбия эшләренең начар куелышы һәм дисциплинаның йомшаклыгы өчен беренче чиратта югары уку йортларының директорлары җавап бирергә тиешләр. Чөнки аларга партия һәм хөкүмәт тарафыннан студентларны политик-тәрбияләү һәм югары квалификацияле белгечләр хәзерләп чыгару кебек мактаулы һәм җаваплы бурыч тапшырылган. Моны бер генә минутка да хәтердән чыгарырга ярамый. Шулай ук студентларны политик-тәрбияләү эшендә, югары уку йортларында тиешле тәртип урнаштыруда партия оешмалары, беренче чиратта, партбюро һәм аның секретарьлары турыдан-туры җаваплылар.

Барлык югары уку йортларында да марксизм-ленинизм нигезләре буенча кафедралар бар, аларның һәр кайсында берничә укытучы эшли. Бу иптәшләрнең һәр кайсына, беренче чиратта кафедра мөдиренә, студентларны политик-тәрбияләү буенча гаять зур бурычлар йөкләтелә. Һәрбер югары уку йортында комсомол оешмасы бар. Алар студентларны политик-тәрбияләү эшендә дирекция һәм партия оешмасына якыннан булышлык итәргә тиешләр.

Партиянең башлангыч оешмаларында булып үткән отчет-сайлау җыелышлары һәм ВКП(б) ның район, шәһәр конференцияләре, шушы көннәрдә генә үзенең эшен тәмам иткән өлкә конференциясе студентлар арасында политик-тәрбия эшләренең куелышындагы зур җитешсезлекләрне күрсәттеләр һәм киләчәктә политик-тәрбия эшен яхшырту буенча конкрет чаралар билгеләделәр. Югары уку йортларының дирекцияләре, партия оешмалары шушы күрсәтмәләрдән чыгып студентларны политик-тәрбияләү буенча үзләренең эшләрен тамрыннан яхшыртырга тиешләр.

Безнең шартларда, социализм иле шартларында, студентларны Сталин эпохасына лаеклы кешеләр итеп, бөек Ватаныбызның кайнар патриотлары итеп тәрбияләү өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Партия оешмаларының бурычы—бу мактаулы һәм җаваплы эшне үрнәк булырлык итеп оештырудан гыйбарәт.

СССР БЕЛӘН ФИНЛЯНДИЯ АРАСЫНДА РАТИФИКАЦИЯ ГРАМОТАЛАРЫ АЛМАШУ

20 нче мартта, Кремльдә, ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы Председателе һәм Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш В. М. Молотов һәм Финляндия республикасы президенты уполномоченныйлары Паасикиви һәм Войнмаа әфәнделәр шушы елның 12 нче мартында Советлар Союзы белән Финляндия республикасы арасында Москвада кул куелган солых договорын, шулай ук солых договорына кушымта булган протоколны ратификацияләү турында грамоталар алмаштылар. (ТАСС).

Тракторлар участкыларга чыгалар

Апас районының Ишеево МТС ы бригадирлары һәм тракторчылары язгы чәчүгә зур күтәренкелек белән хәзерләнәләр. МТС та 10 бригада оештырылды, бригадалар тракторчылар белән тулысынча тәэмин ителде. Хатын-кыздардан бер трактор бригадасы бар. (Иптәш Ж. Фассахова бригадасы).

Бригадирлар һәм тракторчылар 1940 нчы елны һәрбер трактор белән 1.200 гектар эшләргә йөкләмә алдылар.

16 нчы мартта Ишеево МТС ы язгы кыр эшләрендә катнашу өчен 13 тракторны участкыларга чыгарды.

(ТатТАСС).

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК

Чәчү орлыгы белән үзара ярдәмләшү

Чистай районында 17 колхоз үзләренең арткан 2.359 центнер чәчү орлыгын—чәчү орлыгы җитмәгән башка колхозларга бирделәр.

Чәчү орлыклары җитешмәгән колхозларда орлык фонды туплауда колхозчылар актив катнашалар. „Урожай" колхозы членнарының орденлы Никитин, Мансеев, Нестеров һәм Китанов иптәшләр үзләренең арткан ашлыкны чәчү орлыгы итеп колхозга бирделәр. Орлык белән ярдәмләшү „Трудовой путь", „Ударник", „Власть Советов" колхозларында да оештырылды. „Власть Советов" колхозында 50 центнер, „Трудовой путь" колхозында 32 центнер өстәмә рәвештә чәчү орлыгы тупланды.

АЛАБУГАДА АШЫКМЫЙЛАР

Алабуга районы 1939 нчы елны түбән уңыш алды. Моның төп сәбәбе—язгы кыр эшләрен тиешенчә оештырмауда. Аерым колхозларда үткән елны язгы чәчү бер айга якын вакытка сузылды. Районда ике МТС бар. Алар язгы-җәйге кыр эшләре планын үтәмәде. Алабуга районында 1939 нчы елны тракторлар белән эшләү планы бары 70 процент белән калды. Ләкин иген уңышы түбән булуына дип зарланып йөргән район работниклары үткән елгы хаталарны кабатламаска тиешле сабак алмадылар, күрәсең. Чөнки 1940 нчы елгы язгы кыр эшләренә хәзерлекнең начар булуы моны ачык раслый. Язгы чәчү якынлашып килә, ә район чәчүгә хәзер түгел. Авыл хуҗалыгы машиналары һәм инвентарьларга ремонт ясау эше тәгәлләнмәгән. Күп кенә колхозларда транспорт кирәк-яраклары җитми. Күпчелек колхозларда чәчү орлыкларын хәзерләү, чистарту эше тәмамланмаган, орлыкларны агуландыру өчен хәзерлек эшләре алып барылмый. Колхозларда 466 сабан, 133 чәчкеч, 150 культиватор ремонтка керергә тиеш. Тирес чыгару планы 57 процент кына үтәлгән, кар тоту планы 50 процентта тукталып калды.

Атларны язгы кыр эшенә хәзерләү дә мактанырлык түгел.

Алабуга МТС ы да, Морт МТС ы да тракторларга ремонт ясау эшен 1 нче мартка тәмамларга тиешләр иде. Бу МТС ларның беренчесе тракторларга ремонт ясау планын 80 процент, авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау планын 70 процент, икенчесе—тракторларга ремонт ясау планын 37 процент, тагылма инвентарьларга ремонт ясау планын 80 процент кына үтәде.

Язгы кыр эшләренә хәзерлекнең начар булуын район җитәкчеләре белә. Ләкин алар хәлне төзәтү өчен җитди чаралар күрмиләр. Район җир бүлеге работниклары, МТС җитәкчеләре шушындый хәлгә аз гына да борчылмыйлар. Алар канцеляриядә утыралар.

Аерым колхозларда чәчүгә хәзерлек эше тагын да начар. „Путь Ленина" колхозында язга хәзерлек өзелү куркынычы астында. Авыл хуҗалыгы машиналарының бары 50 проценты гына ремонттан чыккан. Бер генә чәчкечкә дә ремонт ясалмаган. Ат сбруйлары хәзерләнмәгән. Шушы вакытка чаклы бары 3 арба ремонтка кергән. Калган арбаларның кайда икәнен дә белүче юк. Агротехника чараларын үткәрү буенча колхоз правлениесе үзендә һичбер җаваплылык сизми.

„Прогресс" колхозында да авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау тәгәлләнмәгән. Монда машиналарны ремонтлау өчен аларның кар астыннан чыкканын көтеп торалар. „Кызыл Татарстан" һәм „Искра" колхозларында да язгы чәчүгә хәзерлек эше шундый ук начар хәлдә. Агротехника чаралары планы үтәлми.

Мондый фактларны бик күп күрсәтергә мөмкин. Алар барсы да район җир бүлеге һәм МТС җитәкчеләренең, районндагы җитәкче оешмаларның язгы чәчүгә хәзерлек эшләренә тиешенчә җитәкчелек итмәүләрен күрсәтәләр.

С. Сафиуллин.

Орденлы Актаныш МТС ының тракторчылар әзерләү курсында укучы курсантлардан Г. Шәймәрданова (сулда) һәм Т. Юлдашева иптәшләр тракторны йөртү буенча практик занятиедә.

А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фото-хроникасы).

МТС һәм МТМ алдынгыларының РЕСПУБЛИКА ПОЧЕТ ТАКТАСЫ

Тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауда югары күрсәткечләр бирүче алдынгылар һәм стахановчылар ВКП(б) райкомнарының һәм хезмәт ияләре депутатларының район советлары башкарма комитетларының күрсәтүләре буенча республика Почет Тактасына кертеләләр:

38. Дәбъяз МТС ының тракторчылары Е. Горшкова, А. Козлова, П. Семенов, П. Иванов, А. Козлов, С. Горшков һәм Ф. Козлов иптәшләр. Алар үзләренә беркетелгән тракторларга һәм тагылма инвентарьларга ремонт ясауны 1940 нчы елның 1 нче январена тәгәлләделәр һәм ремонтка 15 процент экономия ясадылар.

39. Кызыл Армия районының Каргалы МТС ы трактор бригадалары бригадирлары Л. Хәсәенев һәм А. Саматов иптәшләр, бригадир ярдәмчеләре Ю. Миңнегулов һәм Ф. Фатыйхов иптәшләр. Аларның бригадаларында тракторларга ремонт ясау 1939 нчы елның 1 нче декабренә яхшы сыйфат белән тәгәлләнде.

40. Кызыл Армия районының Тат. Ялтан МТС ы трактор бригадалары бригадирлары И. С. Захаров һәм Н. Е. Жирнов иптәшләр. Аларның бригадаларында тракторларга ремонт ясау 1939 нчы елның 30 нчы декабренә яхшы сыйфат белән тәгәлләнде.

41. Кызыл Армия районының Каргалы МТС ы трактор бригадасы бригадиры иптәш Н. Сөләйманов. Аның бригадасында тракторларга ремонт ясау 1940 нчы елның 30 нчы январена яхшы сыйфат белән тәгәлләнде.

42. Кызыл Армия районының Тат. Ялтан МТС ы тимерчесе иптәш Г. И. Жеребенков. Ул тракторларга ремонт ясауда (запас частьләр эшләү һәм реставрацияләүдә) көнлек норманы системалы рәвештә 150—200 процент үтәде.

43. Кызыл Армия районының Каргалы МТС ы тракторчысы иптәш З. Хәсәншин. Ул үзенә беркетелгән тракторга ремонт ясауны 1939 нчы елның 1 нче декабренә тәгәлләде.

Хәзерлек эшләре яхшырды

Тәкәнеш районы, Түбән Биляр авылы, „Кызыл Байрак" колхозы язгы чәчүгә уңышлы хәзерләнү өчен социалистик ярышны киң җәелдерә. Язгы чәчүгә хәзерлек эше ВКП(б) ның XXI нче өлкә конференциясе алдыннан һәм конференция көннәрендә аеруча көчәйде. Стахановчылардан Нәзиров һәм Ибраев иптәшләр җирле ашламалар хәзерләүдә нормаларны көн саен 180 проценттан 300 процентка кадәр үтиләр. Басуга тирес чыгаруда эшләүче иптәшләр дә (мәсәлән, Сәмигуллин, Зиннәтуллина һ. б.) норма үтәүне 180 проценттан 230 процентка кадәр җиткерделәр.

Ярышып эшләү нәтиҗәсендә „Кызыл Байрак" колхозы кар кебек агрономия чаралары планын арттырып үтәде. Тирес чыгару планы 148 процент, кар тоту планы 114 процент, кош тизәге җыю планы 148 процент үтәлде.

Язгы чәчү өчен кирәкле машиналарга һәм инвентарьга ремонт тәгәлләнде. Чәчү орлыклары тартылдылар һәм триерланды.

Гомуми җыелыш карары буенча „Кызыл Байрак" колхозы районының Ташлы Яр һәм Аксыбы авыллары колхозларына социалистик булышлык тәртибендә 70 центнер чәчү орлыгы бирде.

А. Хафизов.

ЯШ ТРАКТОРЧЫЛАР

Тракторчылар хәзерләү өчен Кукмара районының Яңил МТС ы янында оештырылган дүрт айлык курс үзенең эшен тәгәлләде. Курсны барлыгы 52 кеше тәмамлап чыкты. Шуларның 7 се хатын-кызлар. Курсантлардан барсы да тракторчы исемен алдылар. Аларның күпчелеге сынауларны „отлично" һәм „яхшы" билгеләренә тапшырдылар.

(ТатТАСС).

Украина һәм Белоруссиянең көнбатыш өлкәләре сайлаулар алдыннан

ЛЬВОВ

24 нче март көне—Украинаның көнбатыш өлкәләреннән СССР һәм УССР Верховный Советларына депутатлар сайлау көне якынлаша. Польша алпавытлары һәм капиталистлары коллыгыннан Кызыл Армия тарафыннан азат ителгән Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия халыклары Совет дәүләтенең югары власть органнарына беренче тапкыр үзләренең вәкилләрен җибәрәләр.

Өлкә сайлауларга гаять зур күтәренкелек белән хәзерләнә. Барлык районнарда күп кеше катнашы белән партиясез активның киңәшмәләре үткәрелде. Җыелышларда авыл активистларыннан 20 меңгә якын кеше булды.

Массовый-политик эш үзенең нәтиҗәләрен бирде. 400 меңнән артык сайлаучы сайлау алды митингларында һәм җыелышларында катнашты. Аларда 2.500 дән артык кеше—эшчеләр, интеллигенция һәм крестьяннәр фикер алышуларда чыгып сөйләделәр. Алар барсы да коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатларын якладылар.

Хәзер күп меңнәрчә кешеләр түгәрәкләрдә политик тормышка тартылалар.

Агитаторлар түгәрәкләрдә СССР һәм УССР Верховный Советларына депутатлыкка кандидатларның тормыш юллары турында сөйлиләр. Сыра заводының эшчесе, хәзерге вакытта шәһәр советы председателе булып эшләүче иптәш Кармазин, батрачка Мария Перепелица, эшче Кузьминская масса арасында киң күләмдә танылган кешеләр. Совет интеллигенциясе вәкилләре—академик Студинский, профессор Панчишин, профессор Петр Франко, поляк язучысы Ванда Василевская, артист Сталник депутатлыкка популяр кандидатлар.

Сталин Конституциясе һәм сайлаулар турындагы положение белән кызыксыну гаять зур. 18.390 түгәрәктә ярты миллионнан артык сайлаучы Конституцияне өйрәнә. Коммунистларның иң зур күпчелеге сайлау участкыларына агитаторлар итеп җибәрелде. Аеруча хәзерлекле коммунистлар җирле халыктан булган агитаторлар коллективларына җитәкчелек итәләр.

Сайлаучылар коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатларын бердәм рәвештә яклыйлар һәм үзләренең кандидатураларын сөйрәп кертергә маташучы милләтчеләргә кискен отпор бирәләр. Яворов районының Жорниво авылындагы җыелышта, кулаклар округ күләмендәге сайлау комиссиясенә кандидат итеп элекке староста Кульчицкийны күрсәтергә маташканнар. Күп кенә крестьяннәр, шул исәптән хатын-кызлар старостага каршы чыкканнар. Алар Кульчицкийның революцион крестьяннәрне полициягә тотып биргән провокатор икәнлеген фаш иткәннәр.

БАРАНОВИЧИ

1940 нчы елның 24 нче мартында хезмәт ияләре үзләренең сайлау участкыларына барырлар һәм бөек Ватаныбызның иң яхшы улларына һәм кызларына, бөек большевистик партиягә, белорус халкының атасы һәм дусы иптәш Сталинга тавыш бирерләр.

Эшчеләр һәм хезмәткәрләр СССР һәм Белоруссия ССР Верховный Советларына сайлауларга хәзерләнгәндә заводларда, фабрикаларда, тимер юлларда, учреждениеләрдә социалистик ярыш җәелдерәләр. Барановичи станциясенең паровозларга ремонт ясау депосында 500 гә якын кеше социалистик ярышка кушылды.

Партиянең шәһәр комитеты сайлау кампаниясендә коммунистларның һәм комсомолецларның бурычлары турындагы мәсьәлә буенча партиянең шәһәр күләмендәге җыелышын үткәрде. Партиянең һәрбер башлангыч оешмасы сайлау участкысына беркетелде. Агитаторлар занятиеләргә яхшы хәзерләнәләр. Занятие башланганчыга кадәр агитаторлар агымдагы вакыйгаләр турында газеталардан хәбәрләр укыйлар, шуннан соң Сталин Конституциясен һәм сайлаулар турындагы положениене өйрәнергә керешәләр.

Сайлау кампаниясендә комсомол оешмалары зур ярдәм күрсәтәләр. Алар 45 кешене китап йөртүчеләр итеп билгеләделәр, бу иптәшләр сайлаучыларның йортларына китаплар илтәләр. Китап йөртүчеләр сайлаучыларга китап тарату белән генә чикләнеп калмыйлар, бәлки аларга сайлаулар турындагы положениене аңлаталар, газеталардан аерым мәкаләләрне укыйлар.

Агитаторлар сайлаучыларга социализм илендәге уңышлар турында сөйлиләр. Сталин Конституциясенең хезмәт ияләренә нәрсә биргәнлеген аңлаталар, кыска гына вакыт эчендә көнбатыш өлкәләрдә Совет власте тарафыннан ирешелгән уңышлар турында күп кенә мисальләр һәм фактлар китерәләр.

Шәһәрдә сайлаучылар өчен 565 түгәрәк оештырылды. 554 агитатор эшли һәм 14 агитколлектив төзелде. 17.000 кеше сайлаулар турындагы законны өйрәнә. Агитаторлар барсы да кирәкле булган әдәбият белән тулысынча тәэмин ителделәр. Партиянең башлангыч оешмалары депутатлыкка кандидатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрәләр, кандидатларны яклап агитация алып баралар.

Дошман сыйныфларның калдыклары—бундчылар, сионистлар, пепеэсчылар, һәр төрле буржуаз милләтчеләр һәм аларның иярченнәре—социализмның шушы иң явыз дошманнары, сайлауларның уңышлы үтүенә комачауларга, кайбер урыннарда үзләренең пычрак эшләрен үткәрергә маташалар. Шәһәр большевиклары большевистик уяулыкны көчәйтүне, сайлаучылар арасында агитация-масса эшенең сыйфатын яхшыртуны, дошман элементларның барлык казынуларын фаш итүне төп бурыч итеп куйдылар.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

Масса-аңлату эшләре нәтиҗәсе

Чистай районы, Тат. Тәлкыш авылы башлангыч партоешмасы (секретаре иптәш Хәбибуллина) җитәкчелегендә 7 колхоз керә. Партоешма колхозларда политик-масса эшен шактый яхшыртты. Алдынгы хезмәт ияләре арасында партиягә керү омтылышы сизелерлек рәвештә көчәйде. Башлангыч оешма партиябезнең XVIII нче съездыннан соң ВКП(б) га член итеп 3 кешене, кандидат итеп 11 кешене кабул итте. Партия сафларына яңа кабул ителүчеләр арасында колхоз председательләреннән Мөхәметов, Зарипов, „Тәлкыш" колхозының стахановчысы Зәйнидуллин, шул ук колхозның бригадиры һәм авыл советы депутаты Бадыгин, „Шахтер" колхозының агротехнигы Зарипова, алдынгы укытучылардан Хәснуллина, сельпо председателе Баһаветтинов иптәшләр бар.

Яшь коммунистларның һәрберсенә партпоручениеләр бирелде. Алар колхозчылар арасында партия һәм хөкүмәт карарларын аңлату эшен алып баралар. Партоешма үзе тарафыннан бирелгән поручениеләрнең үтәлешен тикшерү эше белән нык шөгыльләнә. Поручениеләрнең үтәлеше турында партҗыелышларында коммунистларның информацияләре тыңлана. Кандидатларга конкрет ярдәм итү арасында, яшь коммунистлар политик яктан яхшы гына үсәләр һәм җитәкче эшләргә күтәреләләр. Мәсәлән, укытучы иптәш Хәснуллина хәзер тулы булмаган урта мәктәп директоры булып эшли. Иптәш Сафин колхозда бригадир булып эшли иде. Ул, колхоз председателе итеп күтәрелде. Иптәш Баһаветтинов сельпо председателе итеп сайланды. Яшь коммунистлар үзләренең эшләрендә зур җаваплылык сизәләр һәм үзләренә тапшырылган эшне яхшы итеп үтәү өчен көрәшәләр.

Мисаль өчен иптәш Мөхәметовны алыйк. Ул, председатель буларак, колхозга большевикларча җитәкчелек итә. Колхозда политик-масса эше җәелдерелде. Язгы чәчүгә хәзерлек һәм аны үткәрү турындагы темага беседалар үткәрелә, кычкырып газеталар уку оештырыла. Колхоз стена газеталары чыгарыла. Колхозчылар арасында социалистик ярыш киң колач алды. Язгы чәчүгә хәзерлектә колхозчы хатын-кызлар актив катнашалар. Колхозда язгы чәчүгә хәзерлек яхшы бара. Агротехника укулары җанлы бара. Чәчүлек орлыклары җитәрлек һәм алар чистартып куелган. Авыл хуҗалыгы машиналарына һәм транспортка ремонт эше күптән тәгәлләнде. Кар тоту планы 125 процент итеп үтәлде.

Башлангыч партоешма җитәкчелегенә керә торган „Шахтер", „Кызыл Алан", „Тәлкыш", „Тубылгы" колхозларында һәм Тельман исемендәге колхозда язгы чәчүгә хәзерлек эшләре күптән тәгәлләнгән иде инде.

Ш. Шакиров.

ПАРТКАБИНЕТЛАРДА

Заинский районы парткабинеты үзенең эшен шактый яхшыртты. Анда ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләрдән укырга һәм консультация алырга йөрүчеләрнең саны сизелерлек дәрәҗәдә арта бара. Парткабинетта хәзер 3.000 нән артык төрле китаплар бар. Быел 36 исемдә политик һәм әдәби журнал һәм 18 төрле газета алына. Китап алып укучылар саны узган елда дистәләп кенә санала иде. Быел даими рәвештә китап алып укучылар районда үзендә генә дә 200 дән артык санала. Шулай ук авылдагы коммунистларның һәм интеллигенциядән бик күп иптәшләр даими рәвештә парткабинеттан китап алып укып баралар.

Көтәпханәдә „Кыскача курс"ның XII бүлеге буенча да күргәзмә материаллар һәм альбомнар бар. Партия тарихын өйрәнүчеләр алардан парткабинетта да һәм өйләренә алып кайтып та файдаланалар.

Парткабинет (мөдире иптәш Сабиров) соңгы вакытта теоретик беседалар оештыру һәм уздыруга игътибарын көчәйтте. Кайбер башлангыч оешмаларда коммунистлар парткабинетка оешкан рәвештә килеп теоретик беседалар уздырдылар. Мәсәлән, уполнаркомзагта һәм райфода эшләүче коммунистлар, берничә тапкыр инде, иптәшләрчә беседалар уздырдылар. Шулай ук башлангыч оешкан рәвештә беседалар уздыру культурасы гына киңәйтелде. Гыйнвар һәм февраль айларында мондый беседаларга бик күп иптәшләр катнашты диярлек булып тордылар.

А. Максимов.

Аксубай райпарткабинеты ВКП(б) тарихы һәм теоретик мәсьәләләр буенча иптәшләргә беседалар үткәрүне үзенең эш практикасында еш куллана башлады. Аерым алганда бу беседалар укытучылар арасында берничә тапкыр үткәрелде инде.

Яңа Узи авылындагы тулы булмаган урта мәктәптә уздырылган теоретик беседага 16 укытучы катнашты. Беседа иптәшләргә „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"ның III нче бүлегенә караган мәсьәләләр буенча алып барылды.

Беренче булып иптәш Гыйләҗев сүз алды. Ул рус-япон сугышы мәсьәләсенә тукталды. Бу сугышның башлануы сәбәпләрен, анда карата большевикларның һәм меньшевикларның нинди мөнәсәбәттә булуларын, бу сугышның нәтиҗәсе итеп Россиядә беренче революциянең тизләтүен ачык аңлатып бирде.

Аннан соң Хәсәншин, Хәйретдинов, Вәлиуллин, Шиһапов, Камалов һәм башка иптәшләр бер-бер артлы чыгып сөйләделәр.

Т. И. Чернов.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК ЭШЕНӘ КОМСОМОЛ ОЕШМАЛАРЫ АКТИВ КАТНАШАЛАР

Арча районының 59 колхозында партиянең башлангыч оешмалары юк. Аларда комсомол оешмалары бар. Бу оешмаларның күпчелеге партиябезнең XVIII нче съезды һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының VIII нче пленумы күрсәтмәләре нигезендә үзләренең эшләрен үзгәртеп кордылар. Шуның нәтиҗәсе буларак, аларның эшләре сизелерлек рәвештә яхшырды. Дәүләт һәм хуҗалык мәсьәләләре белән системалы шөгыльләнә башладылар. Язгы чәчүгә хәзерлектә колхоз правленияләренә көндәлек булышлык күрсәтәләр.

Мисаль Кульятас колхозы янындагы комсомол оешмасын алырга мөмкин. Комсомол җыелышларында колхоз җитәкчеләренең һәм колхоз производствосында эшләүче аерым комсомолецларның информацияләре тыңлана. Хуҗалык һәм язгы чәчүгә хәзерлек эшләрендә кимчелекләрне бетерү буенча конкрет чаралар күрелә.

Бу оешмада 15 комсомолец исәпләнә. Шулардан 13 комсомолец турыдан-туры колхоз производствосының төрле тармакларында эшлиләр. Иптәш Шавалиев бригадир. Аның бригадасы язгы чәчүгә хәзерлек эшен, беренче булып, күптән тәгәлләде. Комсомол оешмасының даими булышлык итүе аркасында, колхоз язгы чәчүгә хәзерлек эшен тәгәлләргә иреште. Бу колхоз үзенең артык орлыкларын күрше колхозга бурычка бирде.

Колхозда агротехниканы өйрәнү түгәрәкләрендә системалы эш алып барыла. Колхозчылар агротехниканы зур кызыксыну белән өйрәнәләр.

Әрнәш колхозы янындагы комсомол оешмасы хуҗалык эшләре буенча колхоз правлениесенә зур ярдәм итә. 15 комсомолецның 9 ы колхоз производствосында эшли. Алар барсы да стахановчылар.

Комсомолец иптәш Шәмсеттинов колхоз председателе булып эшли. Аның җитәкчелегендә колхоз язгы чәчүгә хәзерлектә районда алдынгы колхозларның берсе булып тора.

Колхозда агротүгәрәкләр һәм стахановчылар „мәктәбе" эшләп килә. Агроукулар план нигезендә алып барыла һәм занятиеләр үз вакытында үткәрелә. Колхозчылар түгәрәкләрдә актив катнашалар.

„Уныш" колхозы янындагы комсомол оешмасы язгы чәчүгә хәзерлек эшендә колхоз җитәкчеләренә ярдәм итү өчен оешманың барлык комсомолецларын бригадаларга беркетте.

Ләкин, кайбер комсомол оешмалары дәүләт һәм хуҗалык эшләреннән читтә калалар. Мәсәлән, „9 нчы Съезд" исемендәге колхоз комсомол оешмасы (секретаре иптәш Корбанов) производство мәсьәләләре белән бөтенләй шөгыльләнми. Колхозның язгы чәчүгә хәзерлек эше начар. Агрочаралар үтәлми.

„Мәдәният", „Субаш Аты" „Кызыл Әтнә" колхозлары янындагы комсомол оешмалары да дәүләт һәм хуҗалык эшләре белән тиешенчә шөгыльләнмиләр. Язгы чәчүгә хәзерлектә бу колхозлар җидди кимчелекләргә юл куялар. Ләкин алар комсомол оешмаларының игътибарыннан читтә торалар.

Колхозларның язгы чәчүгә хәзерлеген тикшерү буенча ВЛКСМ райкомы, шушы көннәрдә җиңел кавалерия рейде оештырды. Комсомол оешмалары җиңел кавалерия тарафыннан ачылган кимчелекләрне тиз бетерүдә колхоз правленияләренә көндәлек булышлык күрсәтергә, язгы чәчүне тулы хәзерлек белән каршылауны тәэмин итәргә тиешләр.

Р. Гыйбадуллин.

Киров исемендәге 4 нче номерлы ясалма каучук заводының алдынгы стахановчылары ВКП(б) сафларына керәләр. Рәсемдә: партиянең башлангыч оешмасы секретаре, район советы депутаты иптәш Т. Вәлиуллин (уртада) партия сафларына яңа керүчеләр белән ВКП(б) уставын өйрәнү буенча беседа үткәрә. Сулдан уңга—М. Титова, М. Зенитов һәм Т. Гарифуллина иптәшләр. А. Соболев фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

СЕЗОНЧЫЛЫККА ЮЛ КУЙМАСКА

Политик агитация эшләрен хуҗалык эшләренә дөрес бәйләп алып бару хезмәт ияләрен коммунизм рухында тәрбияләү өлкәсендә яхшы нәтиҗәләр бирә. Массаларның политик һәм производство активлыгын күтәрүдә аның тоткан урны гаять зур.

Тымытык районының Вахитов исемендәге совхозы янындагы башлангыч партоешма моны дөрес аңлады һәм бу өлкәдә шактый уңышларга иреште. Совхозда 22 агитатор бар. Алар эшчеләр һәм хезмәткәрләр арасында 500 дән артык занятиеләр һәм беседалар уздырдылар. Шул ук вакытта анда бер агитбригада да эшли. Бригада тарафыннан оештырылган постановкалар, концертлар алдыннан политик һәм хуҗалык мәсьәләләренә карата докладлар һәм беседалар уздырыла. Галиев, Луконин һәм Сафронов иптәшләр бу эшләрдә зур инициатива күрсәтәләр.

Массовый-агитация өлкәсендә партоешма тарафыннан уздырылган чаралар совхозда хуҗалык эшләрен яхшыртуга зур йогынты ясадылар. Ремонт эшләре планы вактыннан элек үтәлде. Слесарьлардан Зайцев, Инников иптәшләр норманы 130—140 процент, ә токарь иптәш Галимов 170—190 процентка кадәр арттырып үтәделәр.

Агитация эшләре системалы рәвештә алып барылган урыннарда массаларның политик активлыгы һәм производстводагы күтәренкелек торган саен үсә һәм ныгый бара.

Тымытык МТСында тракторларга ремонт ясау планы 1 нче январьга ук тәгәлләнде. МТС эшчеләреннән Дәүләтшин, Яһудин, Сабиров һәм Сәетгәрәев иптәшләр көнлек норманы 200 процент итеп үтәделәр. Автогенщик иптәш Солтанов иске частьләргә реставрация ясауда яңа метод уйлап тапты һәм күп кенә запас частьләргә экономия ясады. Чаллы МТС ы стахановчысы иптәш Корбиев та иске частьләргә реставрация ясауда яхшы үрнәкләр күрсәтте һәм 1.510 сумлык запас частьләргә экономия ясады.

Ләкин кайбер партоешмалар һәм комсомол оешмалары политик-агитация эшен системалы рәвештә алып бармыйлар, аны сезонлы эш итеп карыйлар. Мәсәлән, Буралы һәм Урсай авылларындагы башлангыч партоешмалар сайлау кампаниясе узганнан соң агитация-масса эшләрен, диңгә каршы пропаганда эшләрен бөтенләй оныттылар.

Мондый күренешләр соңгы вакытта Тымытык районында политик-агитация эшенең системалы рәвештә алып барылмавын, кайбер башлангыч партоешмаларның бу эштә сезончылык настроениеләренә бирелүләрен күрсәтәләр. Шул ук вакытта алар, ВКП(б) райкомының агитация һәм пропаганда бүлегенең дә агитколлективларга җитәкчелекне йомшартканлыгы турында җидди сигнал булып торалар.

Н. Халиков.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ XX ЕЛЛЫГЫНА ХӘЗЕРЛЕК

СТАХАНОВЧЫЛАР САНЫ ҮСӘ

Казандагы Трикотаж артеле членнары Татарстанның XX еллыгын производствода яңа җиңүләр белән каршылау өчен зур хәзерлек эшләре алып баралар. Артельдә социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәте торган саен киңрәк колач ала. Шуның нәтиҗәсе буларак, февраль аенда стахановчылар саны 114 кешегә җитте.

Алдынгы стахановчылардан иптәш Хәлиуллина февраль ае планын 219 процент, иптәш Шакирова 173 процент, иптәш Сонина 164 процент, иптәш Хадеева 150 процент итеп үтәделәр. Габитова, Зарипова, Егошина, Дәминова, Валишина, Шәйдуллина, Филипова, Салахетдинова һәм Потапова иптәшләр дә февраль аенда планны шактый арттырып үтәделәр.

Бу иптәшләр артельнең җәмагать эшләрендә дә актив катнашалар. Газета укулар оештыралар, аерым темаларга беседалар үткәрәләр. Гомумән, артельдә масса-аңлату эшләре яхшы гына куелган.

И. Кәрим.

ТЕГҮ ЦЕХЫ АЛДА БАРА

Чистайдагы „Швейни" артеле коллективы орденлы республикабызның XX еллыгын производствода яңа җиңүләр белән каршылау өчен көрәшә. Хәзер артельнең стахановчылары хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү өлкәсендә бик яхшы нәтиҗәләргә ирештеләр.

Комсомолка Гурьянова, Соколова һәм Нәҗметтинова иптәшләр көнлек норманы һәр вакыт 300—350 процент, Казакова һәм Капилова иптәшләр 250 процент итеп үтиләр. Социалистик ярышта тегү цехы коллективы һәр вакыт алда бара. Артель январь ае планын 139 процент, февраль ае планын 157 процент итеп үтәде. Производствода бик яхшы эшләүче стахановчылардан 36 кеше кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнделәр.

К. Исламов.

ЙӨКЛӘМӘЛӘРНЕ НАМУС БЕЛӘН ҮТИЛӘР

Ленин исемендәге завод коллективы Татарстан АССР ның XX еллыгы хөрмәтенә ярты еллык планны срогыннан элек—25 нче июньгә үтәү турында йөкләмә алган иде. Коллектив бу йөкләмәне уңышлы үти. Январь һәм февраль заданиеләре шактый арттырып үтәлде. Март аенда яхшы нәтиҗәләргә ирешә.

Иптәш Евграфов сменасында эшләүче Родионова, Власова, Коробкова, Галиева, Мөхәмәтҗанова, Кочнев иптәшләр һәр көнне норманы арттырып үтиләр. Сменада күп станокчыларга хезмәт күрсәтүгә, күп станокчыларның яңа отрядын тәрбияләүгә зур игътибар бирелә. Бу сменаның яшь эшче хатын-кызлары, цехка әле күптән түгел генә килгән Егорова, Сәмигуллина һәм Төхвәтуллина иптәшләр һәрберсе ике аппаратта эшләүгә күчтеләр.

Цехның иптәш Корнилов җитәкчелек итә торган беренче мастерскоенда Сабирҗанова һәм Гаринцева иптәшләрнең бригадалары алдынгы булып баралар, алар ике айлык планны 135—140 процент итеп үтәделәр һәм март заданиесен дә уңышлы үтиләр.

Заводның төзү бүлегендә эшләүче стахановчы тимерче Тихонов һәм Храмов, электросварщик Поликарпов иптәшләр производствода югары күрсәткечләр бирәләр. Алар барсы да яңа нормаларны 2 тапкырдан артык итеп үтиләр. Иптәш Шумков җитәкчелегендәге котельщиклар бригадасы да яхшы эшли. Бу бригада мартның 15 көнлек планын 170 процентка үтәде.

РЕМОНТ АРТЕЛЬЛӘРЕ

Татремонтпромсоюз артельләре (барлыгы 40 артель) Казанда һәм районнарда индивидуаль заказ буенча кием тегү, аяк киемнәрен һәм өс киемнәрен төзәтү эшләрен алып баралар. Узган ел бу артельләр 18 миллион 300 мең сумлык продукция бирделәр. Еллык план 115 процент үтәлде.

Быелгы план буенча Татремонтпромсоюз артельләре 21 миллион 717 мең сумлык продукция бирергә тиешләр. Алабуга һәм Кукмара районнарында күн эшли торган артельләр төзелә. Аяк киемнәренә ремонт ясау өчен шәһәрнең төрле районнарында 30 га якын киоскы ачыла.

В. ПЕРОВ

ТАТАРСТАН АССР ПРОКУРОРЫ

РАСТРАТАЛАРГА КАРШЫ КИСКЕН КӨРӘШ АЛЫП БАРЫРГА

Дәүләт һәм кооператив милкенә растрата ясауны Совет власте социалистик төзелеш өчен чиктән тыш куркынычлы җинаять дип һәр вакыт карап килде һәм карый. 1926 нчы елны Советлар Союзының хуҗалык хәле турында партиянең Ленинград оешмасы активында ясаган докладында иптәш Сталин болай диде:

„... Халык байлыгын әрәм-шәрәм итүче һәм халык хуҗалыгы интересларына зыян китерергә маташучы карак, ул барыбер шпион яки хиянәтче, аннан да начаррак булмаса.

... Эшчеләр һәм крестьяннәр арасында шундый кампания күтәрергә һәм шундый мораль атмосфера тудырырга кирәк ки, ул караклык мөмкинлеген булдырмаска, кәефле һәм кәефсез каракларга һәм халык хуҗалыгын әрәм-шәрәм итүчеләргә көн күрергә һәм яшәргә мөмкинлек бирмәскә тиеш. Безнең байлыгыбызны әрәм-шәрәм итүдән саклау средстволарыннан берсе—караклыкка каршы көрәш,—бурыч әнә шундый".

Безнең уголовный законнарыбыз совет строеның изге һәм кул тидермәслек булган нигезенә—социалистик милеккә—кул сузучы җинаятчеләргә карата каты җәза билгели, аерым хәлләрдә аларга карата җәзаның иң югары чарасын—атуны куллануга да юл куя (1932 нче ел, 7 нче август законы).

Совет законнарын тайпылышсыз тормышка ашыру өчен көрәшеп, суд һәм прокуратура органнары изге совет җирен һәр төрле җинаятчел элементлардан тазарталар. Алар, социалистик милеккә кул сузучыларга, дәүләт һәм кооператив-колхоз средстволарын туздыручыларга нык удар ясап килделәр һәм ясыйлар.

Ләкин, әйтергә кирәк, безнең республика прокуратурасы органнарының растраталарга һәм растратчикларга каршы көрәш практикасында җидди җитешсезлекләр аз түгел әле. Дәүләт сәүдәсе һәм кооперация системасында растраталарга каршы көрәш буенча эшкә соңгы вакытта республика прокуратурасы йомгаклар ясады. Бу йомгаклар, растраталарга каршы оешкан көрәшнең сәүдә оешмаларының үзләре тарафыннан да, шулай ук суд-прокуратура органнары тарафыннан да тиешенчә алынып барылмавын күрсәтәләр.

Сәүдә оешмаларында учет һәм отчет эшләре тәртипсез хәлдә, ә җинаятчеләр учет һәм отчет эшенең шушылай тәртипсез торышыннан файдаланалар, меңнәрчә сумлык растраталар ясыйлар, дәүләт һәм кооператив милкенә зарар китерәләр. Растраталар турындагы материаллар үз вактында формалаштырылып прокуратура органнарына бирелмиләр. Нәтиҗәдә, растратчиклар күп кенә хәлләрдә җаваплылыктан читтә калалар.

Менә факт. Казан шәһәренең Бауман районындагы „Пионер" магазинының элекке кладовщигы Е. 7.208 сумлык товарны әрәм-шәрәм иткән. Горпромторг исә бу турыдагы материалны 7 ай буена „формалаштырган". Нәтиҗәдә, материал тикшерү органнарына бирелгәнче Е. качып киткән. Шуңа ошашлы хәл Бөгелмә райпотребсоюзында да булган. Райпотребсоюз җитәкчелеге Микулински сельпосының элекке хәзерләүчесе Ю. ның 4.232 сумлык растратасы турындагы материалны ул качып киткәч кенә прокуратурага биргән.

Растратчиклар өстеннән булган материалларны прокуратура органнарына үз вактында бирмәү Ширәмәт райпотребсоюзының, Мамадыш сельпосының һәм башка күп кенә сәүдә оешмаларының эш практикасында система булып әверелгән. Шуңа күрә бу сәүдә оешмаларының җитәкчеләре хөкем ителделәр.

Урыннарда контроль-ревизия органнарының эше дә канәгатьләнерлек түгел. Алар ревизияләрне вактында һәм яхшы сыйфатлы итеп үткәрмиләр. Ревизорларның растратчиклар белән берләшеп эшләүләре турында да прокуратурада фактлар бар. Мәсәлән, Татхлебторгның 69 нчы номерлы магазины (Казан шәһәре, Сталин районы) мөдире Кривов средстволар үзләштерү белән системалы рәвештә шөгыльләнгән. Ә өлкән инспектор Мурзин аны фаш итәсе урында, аның белән эчеп анардан акча алып йөргән. Ул, булачак ревизия көннәре турында Кривовны алдан кисәтеп куйган һәм шуның белән аңа ревизия алдыннан кассаны „тәртипкә" китерергә мөмкинлек биргән. Кривов шул юл белән ике ел буена эш итеп килгән һәм 7 мең сумнан артык растрата ясаган.

Сәүдә оешмаларының җитәкчеләре кадрлар сайлап алуга җидди якын килмиләр, бу эштә җавапсызлык күрсәтәләр. Менә мисаль: Казан шәһәренең Ленин районында райпищеторг директоры Капустин билгесез берәүне агент итеп эшкә алган. Агент булып эшкә керүченең хәтта паспорты да булмаган. Ул 12 көн эшләп, 3 мең сум акчаны ала да качып китә. Капустин аның фамилиясен дә, тора торган урнын да белми. (Капустин хөкем ителде).

Икенче мисаль: Красный Бор районында сельпоның сатучысы итеп Гарипов дигән берәүне алалар. Ул растрата өчен бирелгән җәза срогын үткәреп әле яңа гына лагерьдан кайткан була. Сельпода эшли башлагач озак та үтми, Гарипов янадан растрата ясый. Мондый һәм шуңа ошашлы фактлар сәүдә оешмаларының кадрлар сайлап алу буенча эш практикасында, кызганычка каршы, аз түгел. Бу оешмаларның җитәкчеләренә шуны әйтергә кирәк: мондый хәлләрдә алар сәүдә аппаратын җинаятчел элементлар белән чүпләндерүчеләр һәм аларга булышучылар сыйфатында уголовный тәртиптә җаваплылык алып баралар. Алар, сәүдә һ. б. хуҗалык оешмалары җитәкчеләре, моны бик нык истә тотарга һәм истән чыгармаска тиешләр.

Растраталарга каршы көрәш буенча прокуратура органнарының эшен дә канәгатьләнерлек дип әйтеп булмый. Растраталар турындагы эшләрне тикшерү темплары акрын, эшләрне тикшерү күп кенә хәлләрдә закон белән билгеләнгән срокларда үтәлми. Прокуратура органнарының кайбер работниклары растратчикларга карата либераллык күрсәтәләр. Мәсәлән, Чаллы районы прокуроры иптәш Әхметшин сельпоның сатучысы—растратчик В. гә каршы эш кузгатып, анардан эш буенча тикшерү тәмамланганчы тора торган урыннан прокуратура рөхсәтеннән башка китмәү турында подписка алу белән генә чикләнә. Аны качырмау өчен башка тиешле чараларны күрми. Нәтиҗәдә В. үзенең мөлкәтен яшереп качып китә.

Суд процессларын оештыру һәм үткәрү эше дә тиешле югарылыкта тормый. Суд утырышларында эшләрне караган вакытта прокурорлар җитәрлек инициатива күрсәтмиләр. Алар, дәүләт гаепләүчеләре сыйфатында, растраталар турындагы эшләрнең бары тик өчтән бер өлеше буенча гына суд процессларында катнашалар. Кагыйдә буларак, растраталарга каршы көрәштә суд приговорлары средство сыйфатында файдаланылмыйлар, үткәрелгән процесслар тирәсендә масса-аңлату эше җәелдерелми. Ниһаять, район прокурорларының күпчелеге растраталарны тудыручы сәбәпләрне әледән-әле өйрәнеп, аларга тиешле анализ ясамый. Растраталарга каршы көрәш буенча аларның эш практикасында профилактик чаралар кулланылмый, практикадан килеп чыга торган мәсьәләләр, эштәге җитешсезлекләрне бетерү теләге белән, сәүдә оешмалары һәм башка органнар алдында куелмый. Бу, югарыда әйтелгәннәр, күп кенә прокурорларның инициативасы һәм оештыручылык роле әле җитәрлек булмавы эшнең үз агымына куелуы турында сөйли. Конкрет мисаль булып Ворошилов районы прокуратурасының эше тора. Район прокуроры иптәш Маһиҗанова растраталарга каршы көрәштә һичнинди инициатива күрсәтмәгән.

Җәзалау политикасын үткәрү буенча суд органнарының эш практикасы турында берничә сүз. Бу политиканы үткәрүдә массовый рәвештә бозулар зур урын ала дип әйтеп булмый, әлбәттә. Растратчикларның 85,5 процентына карата җәза чарасы сыйфатында иректән мәхрүм итү кулланыла. Ләкин, прокуратура тарафыннан ачылган фактларга таянып әйтергә кирәк, күп кенә халык судлары растраталар турындагы эшләрне томалап калдыралар, ә Верховный Суд аларның мондый практикасын үз вактында төзәтми. Прокуратура тарафыннан 60 тан артык приговор буенча, аларның йомшак булуы аркасында, протест бирелде. Шуның нәтиҗәсендә, растратчикларга җәза сыйфатында бирелгән төзәтү эше, күпчелек эшләр буенча иректән мәхрүм итү белән алмаштырылды.

Растраталарга каршы көрәш өлкәсендә булган җитешсезлекләрнең кайберләре әнә шулар. Бу, эштә уңышлы яклар юк дигән сүз түгел, әлбәттә. Гомумән җинаятьләргә һәм җинаятчеләргә каршы булган кебек үк, растраталарга һәм растратчикларга каршы көрәш буенча да үзләренең эшендә сокланырлык үрнәкләр күрсәтүче прокурорлар һәм халык тикшерүчеләре бездә аз түгел. Алар җинаятьләрне вактында ачуда һәм җинаятчеләргә карата законнарда күрсәтелгән чараларны куллануда яхшы инициатива күрсәтәләр. Алар арасында Чистай районы халык тикшерүчесе Низамов, Алабуга районы халык тикшерүчесе Айнбиндер һәм башка күп кенә иптәшләрне күрсәтергә була.

Югарыда китерелгән фактлардан нинди нәтиҗә ясалырга тиеш?

Сәүдә һәм хуҗалык оешмалары үзләрендә учет һәм отчет эшләрен, шулай ук кадрлар сайлап алу эшен, кискен рәвештә яхшыртырга тиешләр. Средстволарга һәм товарларга мөнәсәбәтләре булган кешеләрнең эшенә көндәлек контрольне көчәйтергә кирәк. Тикшерү органнары контроль-ревизия органнары белән нык элемтәдә булырга, растраталар турындагы эшләрне тиз (10—20 көн эчендә) һәм яхшы сыйфатлы итеп тикшерүне тәэмин итәргә тиешләр. Суд һәм прокуратура органнары растраталарга каршы көрәшне оештыручы булырга, растратчикларга карата җәзалау политикасын тайпылышсыз үткәрергә тиешләр.

МТС ЛАРДА ДӘҮЛӘТ СУМАЛАРЫН АРТЫК ТОТУНЫ БЕТЕРЕРГӘ

Соңгы ике ел эчендә ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы МТС ларның эшен тагын да яхшырту турында юнәлдерелгән күп кенә карарлар кабул иттеләр. МТС ларны дәүләт бюджетына күчерү әнә шундый карарларның берсе иде.

МТС ларны дәүләт бюджетына күчерү трактор эше планын үтәү, иген уңышын күтәрү һәм гаять зур машина паркының яхшы файдалану өчен бөтен шартларны тудырды. Ләкин Татарстанның күпчелек МТС лары 1939 нчы елны бу шартлардан тулы файдаланмадылар.

1937 нче елны трактор эшләре планы 105 процентка, 1938 нче елны 80,2 процентка үтәлгән иде, ә 1939 нчы елны 77,3 процентка гына үтәлде.

Трактор эшләре планының үтәлмәве МТС лардан дәүләт доходларын кору планының үтәлмәвенә, расходларның артык тотуга сәбәп булды.

Мәсәлән, 1938 нче елны МТСлар 5 миллион 385 мең сум, 1939 нчы елны 8 миллион 800 мең сум артык расход ясадылар. Артык расходларның нигездә тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауда һәм ягулыкка тотылды.

Татарстан Наркомземы дәүләт средстволарын экономия ясау һәм аларны саклык белән тоту турында хөкүмәт күрсәтмәләрен тормышка бик йомшак үткәрә. Мәсәлән, Наркоматның ягулык секторында 3 кешелек инспекция бар. Бу инспекция МТС ларда артык расходларга каршы көрәш алып барырга тиеш иде. Ә үткән ел инспекциянең бөтен эше 15 МТС ны тикшерүдән гыйбарәт булды. Тикшерүләр буенча ачылган җитешсезлекләрне бетерү чаралары да күрмәде.

Союз Совнаркомының карары буенча тракторларга ремонт ясау өчен тотылган расход үтәлгән эшләр планына туры килергә тиеш. Йомшак сөрүгә күчереп исәпләгәндә, тракторга ремонт ясау өчен һәр гектар хисабыннан уртача 3 сум 75 тиен билгеләнә.

Хакыйкатьтә бу карары ничек үтәлә соң?

МТС ларның 1939 нчы елгы отчетлары буенча ремонтка никадәр артык расход тотылганлыкны түбәндәге таблицадан да күрергә мөмкин.

МТС лар	Лимит	Тотылган расход
	1940 нчы елның 1 нче кварталына (мең сумнарда)	
Рождественский	91	241
Алабуга	143	273
Балык Бистәсе	128	252
Биектау	127	240
Актаны	130	238
Тельман	86	188

Башка МТС ларның да күбесендә шул ук хәл.

Ремонтка артык расход тоту авыл хуҗалыгы эшләре вакытында тракторларны техник яктан карап торуның канәгатьләнерлек булмавының һәм кеге-кышы ремонтның сыйфаты начар булудан килә. Бу төп сәбәп. Шуның өстенә бу нормаларны һәм эш бәяләре турында СССР Наркомземының приказы булуга да карамастан, күп кенә МТС ларда ремонт эшчеләренең хезмәтләренә төрлечә түләү һаман да дәвам итеп килә.

Кукмара МТС ында поршиннарны кыру һәм шомарту буенча СССР Наркомземы нормалары 2 сәгать 15 минутка, шатун подшипниклары өстенә кою буенча 3 сәгать 10 минутка арттырылган. Дәүләки МТС ында тракторларга ремонт нормалары 25 сәгатькә арттырылган. Буа һәм Чистай МТМ нарын тикшерү аларда хезмәт хакының ике тапкыр чамасы күтәрелгәнлеген күрсәтә.

Чаллы МТМ ында эш нормаларының киметтелүе нәтиҗәсендә хезмәт хакы фондлары 20 процент артык тотылган. Шул ук МТМ да СССР Наркомземы билгеләгән расчет дисциплинасы да бозыла. Чаллы МТМ ы „ХТЗ“ тракторында валны шомарту өчен 10 сум 20 тиен бәя билгеләгән, прейскурантта исә аның бәясе 5 сум 92 тиен генә куелган.

Ремонтка артык күп расход тоту МТС ларның запас частьларга саксыз караулардан да килә. Бондюг, Норлат, Чури-Бураш һәм Чаллы МТС ларында запас частьларны механикларга, бригадирларга, хәтта тракторчыларга да исәпсез бирәләр, кемгә күпме биргәннәрен исәпкә алмыйлар.

Яки менә ягулык тотуны алып карыйк.

Ягулык 1938 нче елны 1 миллион 38 мең сумлык, ә 1939 нчы елны 1 миллион 240 мең сумлык артык тотылган. Беренче Май МТС ында ягулык 65 мең сумга, Столбище МТС ында—61, Тат. Ходяш МТС ында—60, Буа МТС ында 50 мең сумга артык тотылган.

Әрәм-шәрәм ителгән һәм урланган ягулык 1939 нчы елны гына да 200 мең сумлыктан артты. Тирсә МТС ында нефть базасы кладовщигы нефть продуктларын үлчәп түгел, бәлки чиләкләр белән генә җибәргән. Чаллы МТС ында мичкәләрнең тимер бөкеләре булмау, мичкәләрне ничек эләкте шулай бушату аркасында зур югалтулар килеп чыга. Зайнский МТС ында 21.300 сумлык, Тат. Ялтан МТС ында 19.000 сумлык ягулык җитми. Баулы МТС ында төрле учреждениеләргә һәм кешеләргә 6 тонна нефть продуктлары таратылган. Кукмара МТС ында цистерналарга ремонт ясалмаган, шунлыктан ягулыклар югала. Мондый мисальләрне күп кенә китерергә мөмкин.

Шунсы гаҗәп, ремонт һәм ягулык буенча средстволарга артык расход ясауда гаепле булган работниклардан берсе дә җавапка тартылмаган.

Машина-трактор станцияләре һәм Татарстан Наркомземы дәүләтнең йөз меңнәрчә сум акчасын артык тоту кебек практиканы кичекмәстән бетерергә тиешләр.

Я. Байбурин.

Казан пристанендә навигациягә хәзерлек. Рәсемдә (сулдан уңга): пристаньнең механика мастерскоеның алдынгы мастеры Ф. З. Кадыров, механик Г. М. Светов һәм А. Гыйсматуллин иптәшләр транспортерларга бортлар куялар. И. Галиев фотосы.

Навигациягә хәзерлек

СУДНОЛАРГА ҖӘМАГАТ СМОТРЫ

Куйбышевтагы судноларга ремонт ясау заводында җәмагат смотры үткәрелде. Бу әһәмиятле эшкә партия оешмасы тарафыннан зур игтибар бирелде. Судноларга ремонт ясауның сыйфаты турында үткәрелгән җәмагат смотрына механиклар, капитаннар һәм су юлы транспортының башка работниклары, заводның алдынгы эшчеләре катнаштылар.

Җәмагат смотры ремонтның сыйфатын җентекләп тикшерде. Тикшерү нәтиҗәсендә зур гына кимчелекләр ачылды.

„Юг“ пароходының (капитаны иптәш Белкин) тәгәрмәчләренә монтаж эшләре тәгәлләнде дип акт төзегәннәр. Җәмагат смотры бу эшнең әле тәгәлләнеп җитмәвен ачты. Патрондагы болтларның бер өлеше ныгытылмаган. Баш спицларда валиклар дөрес урнаштырылмаганнар һ. б.

„Руслан“ пароходына карата да шуны ук әйтергә кирәк. Казан арматурасы начар эшләнгән. Пароходның машина бүлеге чиста түгел.

„Азовсталь“ пароходын тикшергәндә бригада тагын да зуррак җитешсезлекләр барлыгын күрде. Биредә зур машинага монтаж эшләре бөтенләй алып барылмый. Батареяларның вентильләре канәгатьләнерлек эшләнмәгән.

„В. Воровский“ пароходына, „В. Чапаев“, „Руднев“, „Л. Громов“, „С. М. Киров“, „П. Федосеенко“ судноларына ремонт югары сыйфатлы итеп үткәрелгән. Җәмагат смотры бригадасы бу судноларга үткәрелгән ремонт буенча бер төрле дә җитешсезлек тапмады.

Судноларга ремонт ясауның сыйфатына нык игтибар бирергә кирәк. Җәмагат смотры бригадасы бу турыда практик киңәшләр бирде. Бу уңай белән завод идарәсендә капитаннарның, механикларның һәм производство активистларының махсус киңәшмәсе булып үтте. Киңәшмә җәмагат смотрын моннан соң ешрак үткәрергә кирәклеген әйтте.

1940 нчы елның навигациясенә хәзерлектә җәмагат смотрының әһәмияте бик зур. Судноларга ремонт ясау заводлары Куйбышев заводының бу тәҗрибәсен үзләрендә киң күләмдә кулланырга тиешләр.

Б. Колпачихин.

Төзү материалларын сынау

Татстройтрестның лабораториясе Татарстан республикасында җитештерелә торган төзү материалларына байтак сынаулар үткәрде. Бу сынаулар республикабызда күп санда төзү материаллары җитештерү өчен зур мөмкинлекләр барлыгын бик ачык күрсәтәләр. Лаборатория бетон кубларын тыгызлау буенча 500, кирпеч буенча 60, известь буенча 20, алебастр буенча 15 сынау үткәрде.

Төзү материаллары җитештерүче иң зур предприятиеләрнең берсе—„Строитель“ кирпеч комбинатының продукциясе сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да канәгатьләнерлек түгел. Лаборатория бу тармакта сынау үткәргәннән соң, комбинат эшләп чыгара торган продукциянең сыйфатын яхшырту өчен кайбер практик чаралар билгеләде.

Бөгелмә комын сынау буенча лаборатория күп кенә кызыклы эшләр башкарды. Бу ком шәһәрнең үзендә һәм аңа якын җирләрдә бик күп. Ул җирле төзелеш өчен китә торган агач материалларын алмаштыруда зур урын тотачак.

Лаборатория Татарстан республикасының XX еллык бәйрәменә республикабызда төзү материаллары җитештерүне арттыру өчен күп кенә практик чаралар күрә.

Укучыларның академик өлгерешләрен системалы рәвештә тикшереп барырга

Балаларны укыту һәм тәрбияләү—ул катлаулы эш. Бу өлкәдә зур уңышларга ирешү укытучылык мастерлыгына нык бәйләнгән. Укытучы гүзәл үрнәкләр бирү өчен укучыны яхшы өйрәтергә, дөрес һәм яхшы тәрбияләргә тиеш.

Баланың көндәлек тормышын, характерын өйрәнү белән бергә аның академик өлгерешен дә системалы рәвештә тикшереп торырга кирәк.

Ләкин Казан шәһәрендәге кайбер мәктәпләрнең аерым укытучылары укучыларның академик өлгерешләрен системалы рәвештә тикшереп бармыйлар. Чиректә бер яки ике тапкыр сорау белән чикләнәләр һәм шуңа карап чирек ахрында укучының өлгерешенә бәя бирәләр. Ул гына да түгел, кайбер предметлар буенча чирекне „начар“ яки „бик начар“ билгеләренә тәмамлаган укучыларның алдагы чиректә яхшы өлгерешләргә ирешүләре өчен дә тиешенчә көрәшмиләр.

Өченче чирекнең яртысыннан күбрәге үтүгә карамастан, 50 нче номерлы урта мәктәпнең VI, VII, VIII нче классларында укучы күп кенә балалар математика һәм немец теле предметлары буенча бер генә билге дә алмаганнар. Мәсәлән, VII-„а“ классында укучы Н. һәм Х. уку елының беренче яртысын немец теле буенча „начар“ билгеләренә, VII-„б“ классында укучы М., Н. һәм Х. математика буенча „начар“ билгеләренә тәмамлаган булганнар. Ләкин хәзерге көндә бу укучылар өлгерәме, яки өлгермиме,—аны бер кем дә белә алмый. Дөресен әйткәндә, математика укытучысы Рәхмәтуллина һәм немец теле укытучы Васильева иптәшләр моны үзләре дә ачык белмиләр. Чөнки бу чиректә алардан бер тапкыр да соралмаган әле. Ни өчен класс журналында бу укучыларның өлгерешләренә билге куелмаган, дигән сорауга иптәш Васильева, алар укымыйлар, хәзерләнмиләр, димәкче була. Иптәш Рәхмәтуллина исә сәгат азлыктан зарлана, имештер, укучыларның өлгерешләрен тикшерергә вакыт җитми.

Мондый җитешсезлекләрне 12 нче номерлы урта мәктәпнең дә кайбер укытучыларында күрергә мөмкин. Мәсәлән, Коләхметова, Хәмзин һәм Нигматуллин иптәшләр укучыларның өлгерешләрен системалы рәвештә тикшереп бармаганнар. VIII—X нчы классларда укучылар күбесе тел-әдәбият буенча III нче чиректә бер билге дә алмаганнар әле. X-„а“ классында 19 укучының 7 сендә, VIII нче класста 21 укучының яртысыннан күбрәгендә бер билге дә юк. Рус теле укытучысы иптәш Коләхметова тарафыннан да шундый ук кимчелек кабатланган.

Менә бу фактлар, укучыларның академик өлгерешләрен системалы рәвештә тикшереп бару эшенең тиешле югарылыкка куелмаганлыгын күрсәтәләр. Чирек буенча бер яки ике тапкыр сорау белән укучының дәресне үзләштерүен дә, ничек өлгерешен дә тулысынча белеп булмый. Менә шуның өчен дә, бер яки ике тапкыр сорау белән чирек ахрында укучының өлгерешенә бирелгән бәя дә тулы һәм дөрес бәя була алмый.

Кайбер укытучылар программа һәм балаларның белем дәрәҗәләре белән исәпләшмичә, укучыларга авыр заданиеләр бирәләр. Мәсәлән, рус теле укытучысы иптәш Максутова (50 нче мәктәп) укучыларга авыр диктантлар яздырган һәм шуңа билге куя барган. Программа буенча үтелмәгән материалларны укучылар, билгеле, белмәгәннәр һәм „начар“ билгеләре алганнар. Шуның нәтиҗәсендә, III нче чирекнең беренче яртысында мәктәп күләмендә рус теле предметы буенча өлгереш аеруча түбән булган. Программа буенча үтелмәгән материалларны укучылардан таләп итү, ясалма рәвештә „начар“ билгеләрен тудыра. Укытучы программа буенча укытырга, программа буенча таләп итәргә һәм укучының өлгерешенә реаль бәя бирергә тиеш.

Класс журналы укучының өлгерешен һәм укытучының эшен чагылдыручы көзге була алсын. Анда укучының өлгерешенә билге куелган кебек үк, дәрестә үтелгән материалларның кыскача эчтәлеге һәм өйгә бирелгән задание дә укытучы тарафыннан языла барырга тиеш. Өйгә бирелгән задание һәм аның үтәлешен системалы рәвештә тикшерә бару, ул, дәреснең органик бер өлеше булып хисаплана. Ләкин кайбер укытучылар моны системага салмаганнар. Мәсәлән, 12 нче мәктәпнең 10 нчы „а“ классы журналының „Дәрестә үтелгән материалларның кыскача эчтәлеген язу“ дигән бүлеген ачсак, январь аенда татар әдәбиятыннан нәрсә үтелгәнлекне һәм өйгә нинди задание бирелгәнлекне белеп булмый. Чөнки анда иптәш Нигматуллин аларны язмаган. Иптәш Коләхметова да шулай ук, рус теле әдәбияты буенча бер дәресне дә язып бармаган диярлек.

Мәктәп дирекциясе мондый җитешсезлекләрне күрә белергә һәм вактында бетерергә тиеш. Моның өчен аерым укучыларның, аерым классларның өлгерешләрен системалы рәвештә тикшерә барырга һәм укытучыларның көндәлек эшләренә контрольлек булдырырга кирәк. 1939—40 нчы уку елын югары өлгереш белән тәмамлау өчен, уку-укыту эшендә социалистик ярыш төп метод булырга тиеш.

РОНО һәм ГОРОНО укытучыларның көндәлек эшенә контрольлекне яхшы оештырган завуч һәм директорларның үрнәкле тәҗрибәләрен башкаларга күчерүне оештырырга тиешләр.

М. Закирова.

„Әдәбият“

(Х. Хәйри. Урта мәктәпләрнең IX нчы класслары өчен дәреслек. Татгосиздат, 1939 ел)

Ленин—Сталин милли политикасын эзлекле рәвештә тормышка ашыру нәтиҗәсендә, татар урта мәктәпләре соңгы елларда нык үстеләр. Бу мәктәпләрдән ел саен йөзләрчә-меңнәрчә яшьләр урта белем алып чыгалар. Бу мәктәпләр өчен дәреслекләр булдыруда да күп кенә эшләр башкарылды. VIII нче класслар өчен күп кенә дәреслекләр тәрҗемә ителү белән бергә, оригиналь әсәрләр дә тудырылды. VIII, IX нчы класслар өчен төзелгән әдәбият дәреслекләрен һәм „Әдәбият теориясе“ дәреслеген шундыйлардан хисапларга кирәк. Без бу мәкаләдә әнә шуларның берсенә—IX нчы класс өчен Х. Хәйри иптәш тарафыннан төзелгән дәреслеккә тукталып китәргә уйлыйбыз.

Урта мәктәпләрнең югары класслары өчен әдәбият буенча дәреслек төзү җиңел эш түгел. Программа буенча бу классларда әдәбият тарихи-әдәби план нигезендә өйрәнелергә тиеш. Татар әдәбияты буенча бу сорауга җавап бирә торган дәреслек төзүне катлауландыра торган кайбер специфик сәбәпләр дә бар. Бердән, бездә марксистик нигездә эшләнгән әдәбият тарихы юк. Хәтта безнең әдәбиятыбызда үзенчә бер эз калдырып киткән теге яки бу язучы турында язылган тулырак материалларны табуы да ансат түгел.

Шушы шартларны исәпкә алганда, мондый дәреслекнең барлыкка килүе шатлыклы бер факт. Шуның белән бергә, тулаем алганда, дәреслекнең уңышлы гына булуын әйтергә кирәк. Дәреслектә моңа кадәр күренмәгән материаллар булу (З. Һади, М. Фәйзи биографияләре һ. б.), күп кенә язучыларның иҗад юлларына шактый тулы анализ бирелү, әсәрләргә ясалган уңышлы анализлар („Безнең шәһәрнең серләре“, „Яңа Кисекбаш“ һ. б.)—болар барсы да аның кыйммәтен үстерәләр.

Дәреслекнең кимчелекләре дә юк түгел. Түбәндә без аларның кайберләрен күрсәтеп үтәбез.

Дәреслекнең башында Толстой һәм Салтыков-Щедрин турында һәм аңарга бәйләп XIX нчы йөзнең икенче яртысындагы рус әдәбияты турында кереш материаллар бирелгән. Авторның күрсәтүе буенча, дәреслекнең бу өлеше рус әдәбияты дәреслеге нигезендә төзелгән. Ләкин, безнең фикеребезчә, монда берничә момент исәпкә алынмыйча эш ителгән. Беренчедән, рус әдәбияты дәреслегенең социологизм сөременнән котылып җитә алмаганлыгын хәтердә тотарга кирәк иде. Икенчедән, бөтен бер нәрсәнең (бу урында кайбер җитешсезлекләр белән эшләнгән дәреслекнең) бер өлешен генә механик рәвештә өзеп алу үзе дә ялгыш нәтиҗәгә китерүе бик мөмкин. Монда да без шундый хәл килеп чыккан димәкче булабыз. Сүз кереш мәкалә турында бара. Бу мәкалә XIX нчы йөзнең икенче яртысындагы рус әдәбияты турында тулы төшенчә бирә алмый. Мәкаләдә бөтенләе белән диярлек, разночинец-демократик әдәбият турында гына сүз бара. Тургенев, Толстой һәм башкаларның „саф сәнгатьче“ләр булуын, яки Толстойның „явызлыкка каршы килмәү“ „теория“сен аклаучы булуы турындагы юлларны гына табып була. Дөрес, мәкалә ахрында бу язучылар да халыкчанлык һәм гуманизм байрагын югары тотучылар төсендәрәк күренәләр. Ләкин бу һич тә җитәрлек түгел. Безнеңчә тулырак һәм баерак материал бирергә мөмкин булыр иде һәм ул дөресрәк булыр иде.

Хәзер, „XX нче йөз башында татар әдәбияты“ мәкаләсенә күчеп, шуны әйтергә кирәк: тулаем алганда, бу мәкаләне дәреслекнең уңышлы мәкаләләре рәтенә кертергә мөмкин. Шактый яңа материаллар тупланган, матур гына фикерләр бар. Ләкин авторның бер фикере белән килешеп булмый. Х. Хәйри иптәш җәдитчелек турында язганда, башта ул бу хәрәкәтнең татар либерал буржуа интересларына туры килүен әйтеп килә дә (70—71 битләр), соңыннан: „Ләкин җәдитчелек хәрәкәте төбендә татар хезмәт иясе халкының уянуы һ. б. чагылдырылды“ дигән фикерне әйтә. (71 бит). Демократик интеллигенциянең, шул исәптән Г. Камал, Г. Тукай һәм башкаларның җәдитчелекне „яклау“ларын үз фикеренә таяныч итеп ала. Мәсьәләне болай кую, бик күп бәхәсләргә урын калдыра. Дәреслектә күрсәтелгәнчә, җәдитчелек XIX нчы йөзнең икенче яртысында башланган хәрәкәт. Аның үзенең тарихи тамры һәм тарихи функциясе бар. 1905 нче ел революциясе шартларында татарлар арасында үсеп чыккан культура яңалыклары (әдәбият, матбугат, театр һ. б.)—болар башка нәрсә. Бу яңалыклар каршында җәдитчелек „яңалык“лары инде искереп калганнар иде. Камаллар, Тукайлар әнә шул яңалыклар өчен көрәштеләр. Шуның өчен бу мәкаләне гомумән ачыкларга, җәдитчелек хәрәкәтенә дә, башкасына да үзенә тиешле бәясен бирергә кирәк.

Кайбер образларга бәя бирүгә күчәбез. Автор З. Һадиның тормышы һәм иҗады турында тулы материал биргән. Тик Хәсән мулла турында берничә сүз әйтергә кирәк. Автор бу образга кирәгеннән артык тукталган. Хәсән мулла турында хәтта әсәрнең үзендә дә шул кадәр сүз юктыр. Инде ахрында автор „ул образга реаль, социал тип итеп карарга“ куша. Хәсән мулла, әлбәттә, социал „тип“, ләкин һич реаль түгел; бәлки ул „замана рухының гади рупоры“ (Маркс сүзләре) гына булып калган. Һәм бу моментта З. Һадиның билгеле бер карашлар белән чикләнгән булуын чагылдыра. Мәсьәләнең әнә шул ягы ачып бирелсә дөресрәк булыр.

Г. Камалның „Бәхетсез егет“ е Закирга бирелгән характеристика белән дә тулысынча килешеп булмый. Автор Закирны нечкә хисле, эзләнүчән табигатле; „саф хисле“ кебек эпитетлар (117 бит) белән сыйфатлый, Закирны мондый юл белән опекага алу тенденциясе бу дәреслектә генә түгел, үткән ел Г. Камалның 60 яшь тулу көннәрендә язылган кайбер мәкаләләрдә дә күренде. Ләкин бу объектив бәя түгел. Дөрес, Закир үз әйләнәсенең корбаны сыйфатында кызгануга лаеклы. Ләкин моңар карап образга автор бирмәгән сыйфатларны өстәп ябыштыруның һич кирәге юк. Өстәп әйтеп китәргә кирәк: 108 нче биттә „Бүләк өчен“ комедиясе турында мондый сүзләр бар: „Г. Камал үзенең комедиясендә әнә шул Әхмәтҗан байлар, аларның колы (?) булып торган Хәмидәләрдән рәхимсез рәвештә көлә“. Ә әсәрдә исә Хәмидәнең коллыгы күренми.

Тукай һәм Гафури турындагы бүлекләргә күчеп, боларның эшләнешендәге бер методик кимчелекне әйтергә кирәк. Бу язучыларның иҗадларына гомуми анализ шактый тулы ясалган булса да, программага кергән аерым шигырьләргә кирәгенчә тукталынмаган, хәтта кайберләре телгә дә алынмаган (Тукайның „Шагыйр“ е, „Бер татар шагыйренең сүзләре“). Монда рус әдәбияты дәреслекләренең бер уңышлы тәҗрибәсеннән файдалану уңайлы булыр иде. Күп кенә дәреслекләрдә лирик әсәрләр тематик яктан төркемләп тикшерелә. Бу—кечкенә генә әсәрләргә дә тукталып үтәргә мөмкинлек бирә. Укыту практикасында да бу бик зур җанлылык китерә.

Тагын бер моментны—кайбер уңышсыз мисальләрне күрсәтеп китәргә кирәк. 146 нчы биттә автор Тукайның хатын-кызларны культурага өндәве турында әйтә дә, шуңар „Хатын-кызлар хөррияте“ н мисальгә ала. Без бу шигырьне, шагыйрьнең үз комментариенә таянып, буржуа интеллигентларыннан көлеп язылган дип йөри идек. Ә Хәйри иптәш бу шигырьдәге әлеге интеллигентның шалтыравык сүзләрен Тукайның үз сүзләре итеп бирә. Шулай ук М. Гафуриның „Кара җылан белән бакалар патшасы“ мисалендә җыланга карата әйтелгән сүзне хезмәт ияләренә әйтелгән итеп күрсәтү дә (174 бит) тупас ялгыш.

Сүз ахрында, бу дәреслекнең чыгуы уңай факт булуын тагын бер кат әйтеп, алдагы басмаларда аерым ялгышлардан арынуын, тагын да тулылануын таләп калабыз.

Х. Сәлимев.

ТАТАРСТАН АССР СОВНАРКОМЫНДА

БАЛАЛАРНЫҢ МӘКТӘПКӘ ЙӨРҮЛӘРЕ ӨЧЕН АТА-АНАЛАРЫНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫКЛАРЫ ТУРЫНДА

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы балаларның мәктәпкә йөрүләре өчен ата-аналарының җаваплылыклары турында карар кабул итте.

Бу карар буенча, мәктәп яшендәге балаларны мәктәпкә җибәрү ата-аналарга һәм үз тәрбиясендә балалары булган бөтен гражданнарга, шулай ук, үзләрендә тәрбияләнүче балалар булган учреждениеләргә һәм алардагы тиешле кешеләргә йөкләтелә. Кемнең дә булса тәрбиясендә булмаган тәрбиячесез һәм ата-анасыз балаларны мәктәпкә йөртү урыннардагы халык мәгарифе органнарына йөкләтелә.

Биредә күрсәтелгән барлык кешеләр һәм учреждениеләр балаларны (балаларның авыруыннан, котелмәгән хәвеф-хәтәрләрдән тыш) барлык уку көннәрендә мәктәпләргә җибәрергә һәм, шулай ук, балаларны аяк киемнәре белән, кием-салым белән, дәреслекләр, дәфтәрләр һ. б. белән тәэмин итәргә тиешләр.

Балаларны мәктәпләргә җибәрүдән баш тартучы кешеләр һәм учреждениеләр шәһәрләрдә—кисәтү һәм 100 сумга штрафка тарту юлы белән, авылларда—кисәтү һәм 50 сумга штрафка тарту юлы белән җавапка тартылачаклар. Бу административ җәзалар административ тәртиптә җәзалар бирү комиссиясе тарафыннан бирелә.

Совнарком бу карарның үтәлешен тикшереп баруны хезмәт ияләре депутатларының район, шәһәр, поселок һәм авыл советларының башкарма комитетларына, мәктәп мөдирләренә, район халык мәгарифе органнарының инспекторларына һәм җаваплы кешеләренә йөкләде.

Чит илләрдә

ЗИЛЬТ АТАВЫНА АНГЛИЯ АВИАЦИЯСЕНЕҢ ҺӨҖҮМЕ

ЛОНДОН, 20 март. (ТАСС). Авиация министрлегенең рәсми рәвештә хәбәр итүенә караганда, кичә Англия авиациясе Германиянең Төньяк диңгездә Зильт атавында урнашкан хәрби-һава базасына һөҗүм ясаган. Белдерүдә әйтелүенә караганда, Германия самолетлары Англиянең яр буйларына, шулай ук Англиянең сәүдә флоты карабларына һөҗүмнәрне шушы атаудан ясыйлар.

Караңгы төшкәч тә башланган һөҗүм 7 сәгат буена—20 нче март иртәсенә кадәр дәвам иткән. Англия самолетлары күп санда бомбалар ташлап, ангарларга, мастерскойларга, док корылмаларына һәм казармаларга зыян китергәннәр. Беренчә бомба Германиянең гидросамолетларына төшкән. Зильт атавын Германиянең төньяк ягы белән тоташтыра торган Гинденбург плотинасына да бомба ташланган. Яр буендагы зенит артиллериясе батареяләре бомбардировщикларга каршы көчле ут ачканнар. Англиянең бер самолетыннан башка барлык самолетлары үз базаларына кайттылар. Бер самолет һәлак булгандыр дип уйлыйлар.

Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Лондонда алынган хәбәрләр буенча, һөҗүмдә Англия авиациясенең Германиягә башка вакытта ясаган нинди булса да башка һөҗүменә караганда күбрәк санда бомбардировщиклар катнашкан.

Рейтер агентлыгының Копенһагендагы хәбәрчесе Англия авиациясенең һөҗүмен Даниянең көнбатыш ярында, шулай ук Роме атавында (Зильт атавыннан төньякта) йөзләрчә кешеләрнең карап торганлыкларын хәбәр итә. Көчле шартлаулар ишетелгән һәм биналарның януы күренгән. Атауда сугыш кирәк яраклары шартлагандыр дип уйлыйлар. Гинденбург плотинасында да зур янгын чыккан. Гельголанд бухтасы ягыннан орудиеләрдән көчле атыш ишетелгән.

Хәбәрченең язуына караганда, бүген иртә белән 8 сәгат 45 минутта Англия авиациясе Зильт атавына янадан һөҗүм ясаган.

ДАЛАДЬЕ КАБИНЕТЫНЫҢ ОТСТАВКАГА ЧЫГУЫ

ПАРИЖ, 20 март. (ТАСС). Гавас агентлыгының хәбәр итүенә караганда, „бүген иртә белән Даладье кабинетының барлык министрләре (хәзерге вакытта Лондонда булган почта һәм телеграф министре Жюльеннан башкалары) кабинетның коллектив төстә отставкага чыгуы турында заявление тапшыру өчен Елисей сараена президент янына киттеләр“.

ЛОНДОН, 20 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Франция президенты Лебрен Даладье хөкүмәтенең отставкага чыгуын кабул иткән һәм шунда ук яна кабинет төзү турында сөйләшүләр башлаган.

ДАЛАДЬЕ ХӨКҮМӘТЕНЕҢ ОТСТАВКАГА ЧЫГУЫНА КАРАТА

ЛОНДОН, 20 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, депутатлар палатасында тавыш бирүнең нәтиҗәләре Даладье хөкүмәтенең хәлен кыенлаштырганнар. Лебренның Даладьега яна хөкүмәт төзүне тапшыруын көтәләр. Бу хөкүмәт, ихтимал, кечерәк кенә хәрби кабинет булыр.

ПАРИЖ, 20 март. (ТАСС). Гавас агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 11 сәгат 15 минутта Лебрен сенат председателе Жанненәне һәм депутатлар палатасы председателе Эррионы кабул итеп алар белән сөйләшкән.

ФРАНЦИЯДӘ ХӨКҮМӘТ ТӨЗҮ ПОЛЬ РЕЙНОГА ТАПШЫРЫЛДЫ

ЛОНДОН, 20 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, яңа кабинет төзү Поль Рейнога тапшырылган. 17 сәгаттә Рейно Елисей сараена килгән.

Рейтер агентлыгының шуннан соңгы белдерүендә, Рейноның Елисей сараенда булганнан соң: „Мин, президентка иртәгә иртә белән тулы җавап бирә алырмын дип ышанам“ дигәнлеге әйтелә. Уйлауларына караганда, Рейно „милли берләшү“ кабинеты төзергә тырышачак, бу кабинетка „сул“ канатның Блюм кебек вәкилләреннән башлап, уң канат вәкилләренә кадәр политик эшлеклеләр керәчәк. Даладьега якын торучы политик эшлеклеләр, Рейно кабинеты составына, хәтта хәрби министр посты тәкдим ителсә дә, Даладье керергә уйламый, дип белдерәләр.

ПАРИЖ, 20 март. (ТАСС). Гавас агентлыгы министрләр кабинетын төзүнең Даладье кабинетында элекке финанс министре булган Поль Рейнога тапшырылганлыгын расләй.

ҺИНДСТАНДА МӨСЕЛМАННАР ОЕШМАСЫН ТЫЮ

ЛОНДОН, 20 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англия—Һиндстан властьлары мөселманнарның каксарлар оешмасын законнан тыш дип игълан иткәннәр. Каксарларның Лаһур якынындагы штаб-квартираларын властьлар басып алганнар.

Пәнҗаб провинциясе хөкүмәте бу оешманың җитәкчеләрен кулга алырга приказ биргән. Каксарларның 50 ләп җитәкчесе, шул исәптән оешманың лидеры Гыйниятулла Әлмәшрикый кулга алынганнар.

Лаһурда сугыш хәрәкәте игълан ителгән. Янда корал йөртү тыелган. 6 ай буена 5 кешедән артык группалап җыелу тыелган. Каксарлар турында нинди булса да материаллар урнаштырырга теләүче газеталар рөхсәт алу өчен бу материалларны властьларга күрсәтергә тиешләр.

***

Мөселманнарның каксарлар оешмасы 1932 нче елны төзелде. Мөселманнар яши торган провинцияләрдә (төньяк-көнбатыш чиге провинциясендә, Пәнҗабта, Синдедә һәм Хәйдерабад кнәзлегендә) аның зур йогынтысы бар. Оешманың 400 мен чамасы члены бар һәм ул хәрби характерда төзелгән: каксарлар бер формадагы кием киеп йөриләр һәм лагерь сборлары үтәләр. Оешмада ныклы дисциплина урнаштырылган. Каксарларның лидеры—Гыйниятулла Әлмәшрикый. Каксарлар „Әлислах“ исемле газета чыгаралар иде.

ВАНЦЗИНВЕЙЧЫЛАРНЫҢ „ХӨКҮМӘТ“ ТӨЗЕРГӘ МАТАШУЛАРЫ

ШАНХАЙ, 20 март. (ТАСС). Кытайдагы япон властьлары Ван Цзин-вей белән берлектә Нанкинда конференция чакыруга ныклы хәзерлек башладылар. Бу конференциядә „Кытайның яңа хөкүмәте“ төзелергә тиеш. Нанкинга Ван Цзин-вей, Кытайның „Милләтче - социалистлар партиясе“ дип аталган нәрсәнең вәкилләре һәм башкалар килделәр. Шунда ук вакытлы Бэйпин „хөкүмәте“ нең Ван Кә-мин җитәкчелегендәге 5 вәкиле һәм Монголиядән 2 „делегат“ килде. Конференциянең ачылу көне әле һаман да игълан ителмәгән. Ванцзинвейчылар зур активлык күрсәтәләр. Алар Япония вәкилләре белән һәм төрле группалар белән нык киңәшләшәләр. Япония һәм ванцзинвейчылар матбугатында „яна хөкүмәт“ төзү тирәсендә зур шау-шу күтәрелде. Японнар басып алган районнардагы халык хиянәтчел „хөкүмәт“ төзүне яклый дигән караш тудыру өчен ванцзинвейчылар турыдан-туры ялган юлына басудан да тартынмыйлар. Мәсәлән, 18 нче мартта ванцзинвейчыларның „Чжунхуа жибао“ газетасында Шанхайның кайбер җәмагать оешмалары тарафыннан гүяки Ван Цзин-вейгә җибәрелгән күп кенә котлаулар басып чыгарылды. Кытай газеталары бу ялганны тиз фаш иттеләр. Аерым алганда алар гүяки Ван Цзин-вейгә котлау җибәргән 10 предприятие эшчеләре вәкилләренең белдерүен басып чыгардылар. Эшчеләрнең бу белдерүендә ванцзинвейчылар газетасының ялганы фаш ителә. Кытай матбугатында шушындый ук белдерүләрне Шанхай муниципалитеты советының һәм Франция концессиясе муниципалитеты советының работниклары да басып чыгардылар.

Японнар һәм ванцзинвейчылар Ван Цзинвейне якларга ризалык белдерүче кытай предприятиеләре хуҗаларына вәгъдә бирүгә дә саранланмыйлар. 18 нче мартта японнарның Шанхайдагы хәрби көчләре командующие генерал-лейтенант Фудзита, әгәр кытай предприятиеләренең хуҗалары Ван Цзин-вей „хөкүмәтен“ якласалар, аларга барлык милекләре кире кайтарып биреләчәкне рәсми рәвештә игълан иткән.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА. Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә, Наньнин—Циньчжоу шоссе юлыннан көнчыгыштарак сугышлар дәвам итә. Монда 17 нче марта кич белән кытайлар япон гаскәрләренең чигенү юлын кистеләр. Наньниннан көньяк-көнчыгыштарак, Линшань тирәләрендә кытай гаскәрләре японнар отрядын чолгап алдылар.

Макао атавында кытай гаскәрләре Шици районында япон позицияләренә каршы һөҗүм алып баралар.

Кантоннан көньякта Синьхой—Хэшань секторында сугышлар бара. Контоннан көнбатыштарак, Самшуй районында да аерым бәрелешләр сизелә.

16 нчы мартта япон гаскәрләре Гуандун провинциясенең төньяк-көнчыгыш өлешендә Сватоу-Чаочжау секторында һөҗүм итүче кытай гаскәрләренә каршы атака ясадылар.

ҮЗӘК КЫТАЙДА. Хунань провинциясенең төньяк өлешендә японнарның сугыш караблары Дунтинху күлендә активлыкларын янадан көчәйттеләр.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА. Шаньси провинциясенең көньяк өлешендә япон гаскәрләре Цзянсянь секторында кытай позицияләренә атака ясадылар.



Выборг шәһәре (1940 нчы елның 15 нче мартында төшерелгән рәсем). П. Трошкин фотосы.

ОСОАВИАХИМНЫҢ БАШЛАНГЫЧ ОЕШМАЛАРЫ ПРЕДСЕДАТЕЛЬЛӘРЕ ӨЧЕН СЕМИНАР

Осоавиахимның Бауман район советы (Казан) районындагы башлангыч оешмаларның председательләре өчен 15 көнлек семинар оештырды. Занятиеләр 20 нче мартта башланды. Семинарда катнашучылар СССР ның эчке һәм тышкы хәле турында, халыкара хәлләр һәм соңгы вакытта булган вакыйгалар турында докладлар һәм лекцияләр тыңлаячаклар.

Аннан соңгы занятиеләрдә гомуми-хәрби хезмәт турындагы закон, Осоавиахимның вакытлы уставы өйрәнеләчәк. Бер үк вакытта башлангыч оешмаларда оештыру эшләре, учет һәм отчет мәсьәләләре буенча да занятиеләр үткәрелә. Шунда ук, семенарда катнашучыларның барсы да, беренче баскыч „Ворошиловча атучы“ значогына норма тапшыру буенча теоретик занятиеләр һәм практик күнегүләр үтәчәкләр.

З. Г.

Яшләр призывка хәзерләнәләр

Ямәширмә (Биектау районы) авылының 1920—21 нче елда туган допризывниклары чираттагы призывка ныклы хәзерлек алып баралар. Допризывниклар һәр көнне икешәр сәгатлек хәрби занятиеләр үтәләр. Запастагы отделение командиры иптәш Хәйруллин бу занятиеләрне оештыруда зур активлык күрсәтә. Допризывниклардан 20 кеше „ПВХО“, 17 кеше „ГСО“ значогына нормалар тапшырды. Алар 4 әр оборона значогы булдыру өчен ярышалар.

Мансур Галиев.

ЯШ ТАМАШАЧЫЛАР ТЕАТРЫ КАНИКУЛ КӨННӘРЕНДӘ

Казандагы Яш Тамашачылар театры укучы балаларның язгы каникулына хәзерләнә. Театр каникул көннәренә Марк Твэнның „Принц һәм теләнче“ повесте буенча С. Михалков тарафыннан эшләнгән „Том Кэнти“ примьерасын куячак.

Театр каникул көннәрендә барлыгы 12 спектакль бирергә һәм 6 меңгә якын балага хезмәт күрсәтергә уйлый.

ШЕКСПИР ТУРЫНДА ЛЕКЦИЯЛӘР

Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры 10 нчы марттан башлап бөек инглиз драматургы Шекспир турында лекцияләр циклы оештырды.

Лекцияләрне Бөтенсоюз Театр Җәмгыятеннән (Москвадан) килгән лектор профессор Морозов укый. Шекспир турындагы лекцияләр театрның алда торган „Ромео һәм Джульетта“ постановкасы өчен, андагы образларны дөрес төшенү һәм гәүдәләндерү өчен зур ярдәм итәчәк.

24 нче мартта „Академия театрларының иҗад үсешләре“ дигән темада лекция укылачак.

Татар халык эпосы „Идегә“ гә 500 ел

Шушы көннәрдә Татарстанның тел һәм әдәбият фәнни-тикшерену институтының, Татарстан Совет Язучылары Союзы белән берлектә утырышы булды.

Утырышта татар әдәбияты тарихын периодизацияләү һәм татар эпосы „Идегә“ турында институтның фәнни работнигы иптәш Л. Җәләйнең информацион докладьы тыңланды. Доклад буенча фикер алышуларда сөйләгән иптәшләрдән Ягфәрев, Н. Исәнбәт һәм С. Баттал иптәшләр „Идегә“ эпосына карата зур тарихи әһәмияткә ия булган конкрет материаллар күрсәттеләр. „Идегә“ эпосының егермеләп вариантта булуы әйтелде. Шулар арасында эпосның академик В. Радлов тарафыннан 1872 нче елны Новосибирский өлкәсендә яшәүче Бараба татарларыннан язып алынган нөсхәсе „Идегә“ эпосының иң тулы варианты булып тора.

Утырыш бу эпосның барлык вариантларын булдырып аны фәнни яктан эшләүне тел һәм әдәбият фәнни-тикшерену институтына тапшырды һәм шул эшне башкару буенча 9 кешедән комиссия төзеде.

Шабанов, Л. Җәләй, С. Баттал, М. Җәлил, Н. Исәнбәт һәм башка иптәшләрдән торган бу комиссия, тиз көндә „Идегә“ нең барлык вариантларын туплап, Татарстан хөкүмәте һәм СССР язучылар союзы алдында „Идегә“ эпосының 500 еллык юбилеен үткәрү мәсьәләсен куярга тиеш.

В. Хаҗиев.

МӘКТӘПТӘ ОБОРОНА ЯРЫШЛАРЫ

80 нче номерлы мәктәп (Сталин районы) укучы балаларының Бөтенсоюз күләмендә үткәреләчәк оборона ярышларына хәзерләнә. Шушы уңай белән мәктәптә масса-оборона эшләре шактый яхшырды. Хәрби белемне үзләштерү өчен ПВХО буенча 4 түгәрәк, ГСО буенча 2 түгәрәк, шулай ук элемтә һәм топография түгәрәкләре төзелде. Бу яна төзелгән 9 түгәрәккә 150 дән артык бала йөри.

Ел башыннан алып 59 укучы Ворошиловча атучы, 68 укучы ПВХО, 12 укучы ГСО значкисты итеп хәзерләнде.

1 нче марттан 10 нчы мартка кадәр мәктәп күләмендә оборона ярышлары үткәрелде. Ярышларда барлыгы 94 укучы катнашты. Алар ату, чаңгыда йөрү, граната ыргыту һәм спортның тагын күп кенә башка төрләре буенча ике группага бүленеп ярыштылар.

Мәктәп ярышларында яхшы күрсәткечләр биргән укучылардан район күләмендәге ярышларда катнашу өчен 30 кешелек команда төзелде.

Су басуга каршы көрәш

Язгы ташу вакытында су басуга каршы чаралар үткәрү өчен Татарстан Халык Комиссарлары Советы янында республика күләмендә гадәттән тыш комиссия төзелде. Комиссия председателе итеп Совнарком председателе урынбасары иптәш Киселев билгеләнде.

Барлык оешмалар ташу суы басарлык булган урыннардагы товарларын һәм башка материалларын кичекмәстән ташытып бетерергә тиешләр. Казан тимер юлы идарәсенә су баса торган урыннардагы йөкләрне күчерү өчен вагоннарны тоткарсыз бирергә һәм юл өзек вакытта районнарга кирәк булачак товарларны ашыгыч рәвештә җибәрергә тәкъдим ителде.

Шәһәрдә һәм аның бистәләрендә су басуга каршы көрәшү өчен Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитеты янында шәһәр комиссиясе төзелде. Волга, Кабан күле һәм Казанка буйларында күзәтү пунктлары оештырыла. Су баса торган йортларда торучыларны күчерү өчен тору урыннары хәзерләнә. Күперләрне, плотиналарны һәм башка корылмаларны бозылудан һәм агып китүдән саклау өчен кичекмәстән чаралар күрелергә тиеш.

Татарстанда

Татарстан Мәгариф Халык Комиссариатының лекцияләр бюросы шәһәрдә түләүле лекцияләр үткәрә. 20 нче мартта Казан Кызыл Армия йортында „Европа сугышы“ дигән темада иптәш Тимофеевның лекциясе булды. 28 нче мартта „Хәзерге заман крепостьлары, ныгытмалары, Мажино һәм Зигфрид линияләре“ дигән темада капитан Щеглов тарафыннан лекция укылачак.

Казан Дәүләт университетында Татарстанның XX еллыгына багышланган спартакиада башланды. Спартакиада физкультураның барлык төрләре буенча үткәрелә. 8 нче мартта чаңгы беренчелеге өчен булган ярышларда 200 физкультурник катнашты. Факультетлар арасында үткәрелгән бу ярышларда беренче урынны физика-математика, икенче урынны география, өченче урынны биология факультетлары алдылар. Шулай ук шахмат-шашка буенча да ярышлар үткәрелде. Спартакиада июньгә кадәр дәвам итәчәк.

Татарстан Радиокомитеты янында халык музыка инструментларын эченә алган кыллы оркестр төзелде. Оркестрга композитор Җәүдәт Фәйзи иптәш җитәкчелек итә. Кыллы оркестр хәзер рус һәм татар совет композиторларының әсәрләре өстендә эшли.

ЛЕВЕНФИШНЫҢ ҖИҢҮЕ

СССР ның көчле шахматчыларыннан гроссмейстер Левенфиш һәм мастер Алаторцев арасында барган ярыш 18 нче мартта тәмам булды. Мәгълүм ки, илнең күптәнге һәм оста уенчысы Левенфиш белән яш һәм талантлы Алаторцевның очрашуы безнең СССР да гына түгел, бәлки бөтен дөнья шахматчылары арасында да зур кызыксыну тудырды. Шахмат белән кызыксынучы меңнәрчә кешеләрдән алып шахматның мастерларына, гроссмейстерларына кадәр бу ярышны зур игътибар белән күзәттеләр.

Моңа кадәр хәбәр иткәнебезчә, ярышның беренче яртысы (7 партия) Левенфиш файдасына тәмам булган иде. Алаторцев 8 нче партияне гаять агрессив стильдә алып барды һәм отып үзенең хәлен бераз яхшырта төште. 9 нчы партия ничья белән тәмам булды. Ләкин 10 нчы партиядә Алаторцев, отуга кискен омтылыш белән уйнау шартларында, үзенең йөрешләре турында уйлауга күп вакыт әрәм итте һәм оттырды. Левенфиш ачыктан-ачык зур тынычлык белән уйнарга керешге һәм партияне кискенләштерү юлына кермәде. 11 нче партия ничья белән бетте. Ә 12 нче партиядә Алаторцев уенны кискенләштерергә тырышып бер-бер артлы 3 пешкасын һәм аннан соң партияне дә оттырды. Бу отышыннан соң Левенфиш, Алаторцевның 4 ярым очкосына каршы 7 ярым очко җыеп, ярышта отуны тәэмин итте.

Гроссмейстер исмен алу өчен Алаторцев ярышта я отарга, я булмаса ничья белән бетерергә (мөмкин булган 14 тән 7 ярым очко алырга) тиеш иде. 12 нче партиядән соң ук Алаторцевның бу мөмкинлеге калмады. 13 һәм 14 нче партияләрнең инде ярышның нәтиҗәсе өчен әһәмияте калмаган иде. Алар икесе дә ничья белән тәмам булдылар һәм Левенфиш ярышта 5 ярым очкога каршы 8 ярым очко белән җиңеп чыкты.

Гроссмейстерның күп еллык тәҗрибәсе һәм уеннарны позиция ягыннан да, тактика ягыннан да бик оста алып баруы бу ярышта аеруча нык сизелде. Алаторцевта исә әле бу сыйфатларның өлгереп җитмәгәнлеге күренде.

Х.

ТЕЛ-ӘДӘБИЯТ УКЫТУЧЫЛАРЫНЫҢ РЕСПУБЛИКА КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Шушы елның 25 нче мартында Татарстандагы тел-әдәбият укытучыларының беренче фәнни-Педагогик конференциясе ачыла. Конференцияне, укытучыларның белемнәрен күтәрү институты белән берлектә, Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты үткәрә. Анда 20 гә якын фәнни доклад тыңланачак. Конференция Казан Укытучылар Йортында ачылып 28 нче мартка кадәр дәвам итәчәк.

Редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕ
Кызыл Армия йортында
23 һәм 24 нче мартта
РСФСР НЫҢ ХАЛЫК АРТИСТКАСЫ, ЛЕНИН ОРДЕНЛЫ
ЕКАТЕРИНА ВАСИЛЬЕВНА ГАЛЬЦЕР ның
балет кичәләре
Балетта Бөтенсоюз Гастроль—Концерт берләшмәсе артистларыннан: Андрей Бабанин (балет), Анатолий Ширвиндт (скрипка), Тамара Высочан (художестволы уку) һәм Иосиф Катон (фортепиано) катнашалар. Кич 9 сәгаттә башлана. Касса һәр көн көндез 2 сәгаттән кич 8 гә кадәр ачык. 1—1

ИГТИБАР ИТЕГЕЗ!
„Красная Татария“ „Кызыл Татарстан“
издательствосының өлкә газеталарына, шулай ук барлык үзәк газеталарга апрельдән алып 1940 нчы елның барлык срокларына
ПОДПИСКАЛАР АЛУ ДӘВАМ ИТӘ
Казанда подпискалар: үзәк газеталарга шушы ел 26 нчы мартка кадәр, ә өлкә газеталарга 29 нчы мартка кадәр алына.
Газеталарга подписка бирү эшен подписка алу срогының соңгы көннәренә калдырмагыз. Подпискаларның вактында бирелүе газета-журналларның тәртипле килүләрен тәэмин итә.
Подпискалар предприятиеләрдәге һәм учреждениеләрдәге матбугат таратучыларда, Союзпечать инструкторларында, почтальоннарда һәм почта бүлекләрендә алына.
Подпискалар буенча белешмәләр: Бауман районында 1—88, Молотов районында 10—33, Сталин районында 8—33, Киров районында 95, Ленин районында 11—86 телефоннары буенча бирелә.
Районнарда белешмәләр—почта конторларында һәм почта бүлекләрендә бирелә.
Искәрмә: „Кызыл Татарстан“, „Красная Татария“, „Правда“, „Известия“ һәм „Комсомольская Правда“ газеталарына подпискалар билгеләнгән лимитларны исәпкә алу нигезендә алына.
Шулай ук, „Татарстан большевигы“, „Азат Хатын“, „Чаян“ һәм „Пионер каләме“ журналларына подпискалар алу дәвам итә.
„Издательство“ һәм „Союзпечать“.

Казанда (Кече-Галактионов урамы, 24. Телефон 3—76)
А. М. ГОРЬКИЙ МУЗЕЕ АЧЫЛДЫ
Музей эш көннәрендә көндез 12 сәгаттән кич 6 га һәм гомуми ял көннәрендә көндез 10 сәгаттән 4 кә кадәр ачык.
Атнаның 1 нче көннәрендә музей эшләми.
510—2—1

Казан шәһәре Киров райкомхозы барлык предприятиеләргә һәм оешмаларга белдерә:
Казанкадагы 1 нче номерлы тегермәннең суы 25 нче мартта җибәрелү уңае белән, бирге Устьедә
КАЗАНКА ЕЛГАСЫНДАГЫ КЫЗЫЛ БИСТӘ КҮПЕРЕ 23 нче МАРТТА СҮТЕЛӘ
528—1

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
Бүген 22 нче һәм 24 нче мартта кич
ИРЕК
24 нче мартта көндез
ФАЙДАСЫЗГА САКЛАНУ
Талоннар белән кертелми.

Киров районындагы
КУЛЬТУРА САРАЕНДА
Яш Тамашачылар театры спектакльләре
23 нче мартта
БАЛЬЗАМИНОВНЫҢ ӨЙЛӘНҮЕ
24 нче мартта
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
Талоннар белән кертелми. Кич 8 сәгатьтә башлана.

КАЗАН АВТОМӘКТӘБЕ
производстводан аерып һәм аерымыйча укытып III нче класс шоферлар әзерләү курсларына (көндезге һәм кичке группалар)
УКУЧЫЛАР АЛА
Казан, Кызыл Армия урамы, 16.
408—5—5

Центроэлектромонтаж трестының Казан конторасына, Казанда һәм районнарда эшләү өчен — БАРЛЫК РАЗРЯД ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР, ЭЛЕКТРОСЛЕСАРЬЛАР, ПРОИЗВОДСТВОЧУ БУХГАЛТЕР һәм ГАДИ ЭШЧЕЛӘР кирәк. Казан, Банк урамы, 13.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 22 нче мартта
ЛЕНИН
23 нче мартта
МАСКАРАД
Талоннар белән кертелми.
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр касса ачык.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәр кич
ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ
ЦИРК УЕНЫ
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“	ТАШЛАНДЫК
„УНИОН“	Премьера ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“	Документаль фильм БЕЗНЕҢ КИНО
„ЧАТКЫ“	ДУБРОВСКИЙ
„ПИОНЕР“	ШӘХСИ ЭШ
„Колхозник“	Гроза
„РОТ-ФРОНТ“	ПАТРИОТ
КУЛЬТУРА САРАЕ	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП

Казан Коммуналь Төзелеш Инженерлары институтының югалган гербы печатен гамәлдән чыккан дип санарга. 523—1